| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№ 136__**

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль
районында мәдәниятне үстерү» муниципаль
программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 20 декабрендәге 822 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
10.02.2020 елның 136 номерлы карарына
кушымта

# «Кукмара муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме Программаны | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа**)** |
| Программаның заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче, программаны тормышка ашыру координаторы | «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе<br>«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе<br>«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге |
| Программаның максаты: | Мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру.<br>Мәдәни-ял итү эшчәнлеге өлкәсен үстерү.<br>Китапханәнең, китапның, укуның иҗтимагый әһәмиятле статусын, шулай ук кулланучыларның гомуми һәм мәгълүмати культура дәрәҗәсен арттыру өчен китапханәнең потенциаль мөмкинлекләрен куллану һәм нәтиҗәлелеген арттыру хисабына  күтәрү өчен шартлар тудыру,<br>Кукмара туган якны өйрәнү музее фондларын тулыландыру (архив материаллары, фәнни-тарихи ядкарьләр, сәнгать кыйммәтләре, этнографик, топонимик һәм фольклор материаллар җыю буенча экспедицияләр үткәрү).<br>Район территориясенең йөзен (имидж) формалаштыру. |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасының Кукмара муниципаль районында гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә архив эше белән идарә итү. |
| Программаның бурычлары | Район халкының төрле катламнары арасында халык иҗаты традицияләрен алга этәрү һәм заманча таләпләргә җавап бирә торган үзешчән иҗатны гамәлгә ашыру буенча мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген оештыру өчен шартлар тудыру;<br><br>Традицион халык мәдәниятенә, үзешчән сәнгати иҗатка һәм һөнәри сәнгатькә ярдәм итү;<br><br>Традицион район чаралары системасын саклау һәм үстерү;<br><br>Гражданнарның район музей һәм китапханә фондларының мәдәни һәм мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү;<br><br>Китап укуга һәм халыкның барлык категорияләрен китапханәдән файдалануга җәлеп итү, китапханәнең абруен һәм ролен күтәрү;<br><br>Китапның, китап укуның һәм китапханәнең мәгълүмат ресурсларының бай потенциалын ачу;<br><br>Әдәбият турында мәгълүмат бирү системасын оптимальләштерү һәм китапханә-мәгълүмати хезмәт күрсәтүне камилләштерү;<br><br>Укучыларга укуны алга этәрүгә ярдәм итүче социаль-кыйммәтле китап-журнал, аудиовизуаль һәм мультимедиа продукциясе бирү өчен максималь уңай шартлар тудыру;<br><br>Уку өлкәсендә эшләүнең яңа формаларын һәм методларын апробацияләү;<br><br>Барлык кызыксынучы затлар һәм оешмалар белән уку-укыту эшчәнлегенә ярдәм итү һәм аны алга этәрүдә хезмәттәшлек;<br><br>Мәгълүмат җыю, халыкка тапшыру һәм бирүнең яңа технологияләрен кертү;<br><br>Халыкка Интернеттан ирекле файдалану мөмкинлеге бирү; |

| | |
|---|---|
| | Шәһәр халкын мәгълүмати җәмгыять шартларында актив эшчәнлеккә әзерләү<br><br>Иҗтимагый әһәмиятле проектларны, интеллектуаль ял программаларын эшләү һәм тормышка ашыру;<br><br>Кирәкле матди-техник база булдыру;<br><br>Музей, экскурсия, ял эшчәнлегенең заманча формаларын үстерү.<br><br>Күргәзмә эшчәнлеген киңәйтү, башка музейлар белән экспозицияләр алмашу.<br><br>Төрле социаль-яшь һәм белем бирү төркемнәренең мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, халыкка музей хезмәте күрсәтүне оештыру.<br><br>Музей ишегалдын төзекләндерү.<br><br>Кукмара шәһәре һәм Кукмара районының тарихи-мәдәни саклау зоналары проектларын эшләү.<br><br>Кукмара муниципаль районы тарих һәм мәдәният күчемсез һәйкәлләрен реставрацияләү һәм реконструкцияләү:<br>Танькино авылындагы Петропавловск чиркәве (1811 – 1822), сәүдәгәр Үтәмишевлар йорты, Мәчкәрә авылындагы беренче Собор мәчете, Мәчкәрә авылындагы икенче Собор мәчете, Түбән Өскебаш авылында Геройлар Аллеясы.<br><br>Музей экспонатларын реставрацияләү:<br>Җигүле транспорт, Володиннар предприятиесе эшләнмәләре, фабрикант Комаров җиһазлары.<br><br>Музей фондларын комплекслы автоматлаштырылган музей мәгълүмат системасы программасына кертү (КАМИС).<br>Кукмара районы оешуга 90 ел тулуга багышланган экспозицияне яңарту.<br>Казан шәһәрендә Сабантуй бәйрәмендә «Татар халкының көнкүреше» экспозициясен төзү.<br>«Самавыр бәйрәме» үткәрү, Кукмара авылы Володиннар предприятиесендә бакыр эшләнмәләрен җитештерү тарихы буенча буклет әзерләү һәм бастыру.<br>Кукмара районында туып-үскән танылган шәхесләрнең юбилей даталарына һәм Кукмара районы предприятиеләре |

| | |
|---|---|
| | төзелүнең юбилей даталарына багышланган бәйрәм чаралары һәм күргәзмәләр үткәрү.<br><br>Мәдәният өлкәсендә кадрлар потенциалын саклап калу һәм яңарту.<br><br>Мәдәният өлкәсе инфраструктурасын үстерү.<br>Учреждениенең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.<br><br>Район территориясен алга җибәрү, районны бердәм мәгълүмати һәм мәдәни киңлеккә (пространство) кертү.<br><br>Татарстан Республикасы Архив фонды һәм башка архив документларын саклауны, исәпкә алуны, комплектлауны һәм куллануны тәэмин итү. |
| тормышка ашыру вакыты Программаны | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. «2018 – 2020 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы;<br>2. «2018 – 2020 елларга Кукмара районы халыкларының мәдәни мирасын саклау, торгызу һәм популярлаштыру. Халык иҗатына ярдәм» ярдәмче программасы;<br>3. «2018 – 2020 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасы;<br>4. «2018 – 2020 елларга архив эшен үстерү» ярдәмче программасы. |
| Программаны финанслауның күләме һәм чыганаклары | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме<br>429 263,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 – 140 283,4 мең сум<br>2019 – 152 349,8 мең сум<br>2020 – 136 630,1 мең сум<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Мәдәни хезмәтләр ассортиментын киңәйтү. Мәдәни чараларның һәм хезмәтләрнең файдалану мөмкинлеген арттыру. Халыкның күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсен күтәрү. |

| | |
|---|---|
| | Китапханәнең мәгълүмати, мәдәни, агарту һәм социаль функциясен көчәйтү.<br><br>Кулланучыларның төрле төркемнәренең китап укуга, китапка, мәгълүмати ресурсларга мотивациясен арттыру.<br><br>Кулланучыларның заманча ихтыяҗларына туры килә торган көчле мәгълүмати ресурслар булдыру;<br><br>Шәхси, иҗади, мәдәни һәм интеллектуаль потенциалларын гамәлгә ашыру буенча халык өчен мөмкинлекләрне киңәйтү;<br><br>Яшь буында гражданлык хисләре барлыкка килүенә һәм тулаем алганда районның барлык торак пунктларында да уңайлы социаль мохит булдыруга йогынты ясау;<br><br>Фондның оптималь саклау режимын һәм сакланышын тәэмин итәчәк;<br><br>Район китапханәчеләренең квалификациясен күтәрү системасын булдыру;<br><br>Музей фондларын тулыландыру, тарихи һәм мәдәни мирасны саклау.<br><br>Тарих һәм архитектура һәйкәлләрен саклау.<br><br>Тарихи мирасның сакланышын контрольдә тоту.<br><br>Электрон мәгълүматлар банкын булдыру (КАМИС).<br><br>Милли мәдәниятне саклау һәм үстерү.<br><br>Электрон һәм традицион ресурслардан файдаланучыларга уңайлы шартлар тудыру.<br><br>Мәдәният өлкәсе белгечләренең һөнәри компетентлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.<br><br>Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту.<br><br>Мәдәният учреждениеләре җиһазларын модернизацияләү. |

| | |
|---|---|
| | Мәдәният учреждениеләрен эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итү.<br><br>Программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга кадәр түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>муниципаль архив биналарының архив документларын даими саклауны тәэмин итүче норматив шартларга туры килү-килмәү дәрәҗәсен – 88,9 процентка кадәр;<br>муниципаль архив тарафыннан билгеләнгән срокларда башкарылган соратуларның өлешен бер ел эчендә кергән соратуларның гомуми күләменең 98,3 процентына кадәр. |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру | Программа үтәлешен түбәндәгеләр контрольдә тота:<br>Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты «Кукмара муниципаль районының Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе.<br>«Кукмара муниципаль районы мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе Программаны тормышка ашыру буенча эшне координацияли, аның үтәлеше турында Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына ел саен 1 февральгә кадәр мәгълүмат бирә.<br>Программаны гамәлгә ашыру кысаларында бюджет акчаларын тотуны контрольдә тоту законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла |

## 2. Программаның техник-икътисадый нигезе

Дәүләтнең социаль-икътисадый үсеше өлкәсендәге бурычларны хәл итү турыдан-туры эшчәнлекләре гражданнарның мәдәни тормышта катнашу хокукларын тәэмин итү өчен генә түгел, ә гомумән гражданлык җәмгыятен үстерү өчен дә мөһим факторларның берсе булган мәдәният учреждениеләренә карый.

2018 – 2020 елларга мәдәниятне үстерү Программасы Кукмара муниципаль районы халкын мәдәни үстерү программасының максатларын һәм бурычларын үтәү, халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аларга мәдәният хезмәтләре күрсәтү һәм әлеге системаның киләчәктә камилләшүен тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып эшләнгән.

Программа мәдәният өлкәсендә Россия Федерациясенең дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга, бдәүләт башкарма хакимият органнарының, җәмәгатьчелекнең мәдәни-ял эшчәнлеген оештыруга, балалар һәм яшьләр мохитендәге тискәре күренешләргә каршы торуга, балалар хокукларын саклауны тәэмин итүгә игътибарны көчәйтүгә юнәлдерелгән.

Программа Татарстан Республикасы Кукмара районында мәдәни-ял итү эшчәнлеген үстерүнең кыйммәтле-мәгънәле максатчан, эчтәлекле һәм нәтиҗәле өстенлекләрен билгели, үзгәрешләрнең төп алымнарын һәм механизмнарын бирә.

Кукмара муниципаль районында 123 торак пункт бар, аларда 51 114 кеше яши (Кукмара шәһәрендә 17 700 кеше). Аларга 130 мәдәният учреждениесе (78 – мәдәният йорты, 1 автоклуб, 49 китапханә, 1 Туган якны өйрәнү музее, 1 балалар сәнгать мәктәбе) хезмәт күрсәтә.

Кукмара муниципаль районы мәдәният идарәсенең эш системасы торышы уңай нәтиҗәләр белән характерлана.

Халыкка мәдәни белем бирүнең күп вариантлы челтәре булдырылган.

Район мәдәният йорты һәм авыл мәдәният йорты базасында мәдәни эшчәнлек актив үсә.

Балалар, яшүсмерләр, яшьләрнең гомуми һәм өстәмә белем бирү мәдәният учреждениеләрен бердәм белем бирү киңлегенә интеграцияләү гамәлгә ашырыла, анда һәр учреждение үз үзенчәлеген саклый.

Мәдәни-ял итү эшчәнлегенең эчтәлеген, халыкның үзгәреп торучы запрослары нигезендә формаларны һәм технологияләрне яңарту, хезмәтләрнең барлык өлкәләрен модернизацияләү концепциясен тормышка ашыру процессы бара.

Программа-методик һәм мәгълүмати тәэмин итүне камилләштерү гамәлгә ашырыла. Методик хезмәтләр (методик берләшмәләр, өйрәтү семинарлары) тотрыклы эшли.

Кадрлар белән эшләү сыйфат ягыннан яхшырды.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы мәдәният идарәсенең мәдәни ял итү эшчәнлеген үстерү дәрәҗәсен билгеләүче төп факторлар:

- Кукмара муниципаль районы хакимияте тарафыннан игътибар һәм кайгырту;
- норматив-хокукый базаны камилләштерү;
- ведомствоара хезмәттәшлек – балалар һәм олылар иҗатын тәрбияләүнең төрле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советлары комиссияләре эшчәнлеге;
- башка районнар белән традицион мәдәниятара элемтәләрне ныгыту һәм үстерү.

Китапханә ул – зирәклек, аралашу, белем һәм игелек гыйбадәтханәсе генә түгел. Ул, барыннан да элек, һәркемгә ачык заманча мәгълүмат үзәге. Соңгы вакытта безнең тормышта күп нәрсә үзгәрде, китап укучыларыбыз да бераз башка, кызганычка каршы, аларның китапка мөнәсәбәте үзгәрде. Мәгълүм ки, бүген аны күп очракта мәгълүмати технологияләр алмаштыра. Ашыкмыйча, уйланып китап укучылар саны кими. Тиз, мобиль кулланучылар арта бара. Әлбәттә, компьютер, Интернет һәм уку үзара ярашалар. Китапханәләрнең хәзерге шартларда эшләү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бу ярашу урынлы гына түгел, файдалы да. Хәзерге китапханә төрле категория китап укучыларының запросларына, алар теләсә нинди мәгълүматны яки теләсә кайсы сорауга җавапны аның өчен уңайлы форматта – кәгазьдә яки электрон рәвештә таба алсын өчен,  туры килергә тиеш. 2018 – 2020 елларга китапханәне үстерүнең әлеге Программасы нәкъ шуны күздә тота.

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең заманча укучыга хезмәт күрсәтү өчен шактый саллы матди-техник базасы бар. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ярдәме белән 5 мобиль китапханә

җиһазландырылган, 49 китапханәнең барысында да компьютерлар бар, шуларның 46 сы Интернетка тоташкан, барлык китапханәләр дә күчереп алу-күбәйтү техникасы белән җиһазландырылган.

«Кукмара муниципаль районы ҮКСы» МБУ укучылары саны 33141 кешедән артып киткән очракта, китапханәчеләр елына 1 укучыга 0,58 яңа китап, ягъни район кешесенә 0,39 китап сатып ала, үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китап фондының 70% ы мораль яктан искергән.

Шулай итеп, басма еллары буенча фонд составы Россия китапханәләр ассоциациясе тарафыннан кабул ителгән массакүләм китапханәләр эшчәнлегенең Модель стандарты тәкъдим иткән нормативларга туры килми. Моннан тыш, китапларның күбесе бердәнбер нөсхәдә керә һәм, шуның нәтиҗәсендә, укучы запросларын канәгатьләндерә алмый һәм тиз арада искерә, шул рәвешле, китап фонды составында җитешсезлекләр барлыкка килә.

Район китапханәләренең тышкы һәм эчке эшчәнлегенә анализ түбәндәгеләрне күрсәтте: үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китапханәләреннән барлык буын кешеләре даими файдаланалар. Кулланучыларның төп өлеше – балалар һәм яшьләр: мәктәп, лицей, гимназия, көллият укучылары. Кулланучыларның киләсе төркеме – халыкның социаль яктан якланмаган катламнары (пенсионерлар, инвалидлар, эшсез гражданнар), алар өчен китапханә – бушлай булган бердәнбер мәгълүмат һәм мәдәният учагы.

Районның муниципаль мәдәният учреждениеләре соңгы елларда һәвәскәр иҗат берләшмәләре, халык иҗаты коллективлары, кызыксынулар буенча клублар, гаилә иҗат коллективлары белән эшләүдә билгеле бер тәҗрибә тупладылар, мәдәният өлкәсендә халыкның төрле катламнарының төп ихтыяҗларын билгеләделәр.

Шул ук вакытта, алдагы Программаның кайбер казанышларына карамастан, тармакта кайбер проблемалар хәл ителмәгән булып кала бирә.

Барыннан да элек, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең матди-техник базасының йомшаклыгы, ә нәкъ менә:

янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә акча булмау;

учреждениеләрнең заманча компьютер техникасы белән тәэмин ителешенең түбән дәрәҗәсе.

техника һәм җиһазларның җитәрлек булмавы;

биналарга капиталь һәм косметик ремонт кирәклеге;

мәдәният учреждениеләрендә җиһазларның сакланышын тәэмин итү зарурилыгы (тәрәзә рәшәткәләре, тимер ишекләр);

искергән җиһазлар;

сәхнә костюмнары белән тиешенчә җиһазландырылмау;

китап фондын мультимедиа продукциясе, Электрон ресурслар белән тулыландыру өчен акча җитмәү;

2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы мәдәният идарәсе эшчәнлегенең төп максаты – мәдәни тормышның иң яхшы традицияләрен саклап калу һәм әлеге өлкәдә халыкның максималь мәшгульлеген тәэмин итү нигезендә районның мәдәни-ял итү эшчәнлеге системасын үстерү.

Куелган максат һәм тәкъдим ителгән ориентирларга туры китереп, районда мәдәни-ял итү эшчәнлеге өлкәсендә төп бурычлар комплексын үтәргә кирәк:
- район халкының рухи ихтыяҗларын югары дәрәҗәдә канәгатьләндерү;
- халыкның барлык категорияләре өчен дә ял итү эшчәнлегенең үтемлелеген арттыруны тәэмин итү;
- күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген, үтемлелеген һәм сыйфатын арттыру;
- мәдәният учреждениеләрен эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Тармакны техник модернизацияләү проблемасы аеруча актуаль: учреждениеләрнең сәхнә җиһазлары, ут-тавыш аппаратурасы, музыка инструментлары һәм җайланмалары белән тәэмин ителеше. Бу проблеманың якындагы елларда ни дәрәҗәдә уңышлы хәл ителүенә учреждениеләр тарафыннан халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең санын арттыру һәм сыйфатын яхшырту һәм бюджеттан тыш керемнәрнең артуы бәйле.

Район өчен территориянең имиджын формалаштыру һәм яхшырту, «кулланучылар территориясе» максатчан төркемнәрен билгеләү бик мөһим, болар территорияне үстерүнең озак вакытка исәпләнгән программаларын гамәлгә ашыру өчен инвестицияләр җәлеп итәргә ярдәм итәчәкләр, бу исә районның мәгълүмати яктан алга китүенә китерә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль архивының документлар фондлары Татарстан Республикасы Архив фонды составына керә һәм Кукмара районының күп милләтле халкының тарихи, сәяси, икътисади, фәнни, социаль, мәдәни, матди һәм рухи мирасы, мәгълүмати һәм интеллектуаль байлыгының мөһим өлеше булып тора. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль архивы – 40174 саклау берәмлеге булган 172 фонд. Шуларның 26810 саклау берәмлеге – идарә документлары; 13307 саклау берәмлеге – шәхси состав буенча документлар; 57 саклау берәмлеге – шәхси чыгыш документлары; 40 фотодокумент. Документлар 1930 – 2015 еллар белән даталана. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты архив бүлегенең документлар фондларында анда районның социаль-икътисади үсешен, аның үсешенең төрле этапларында яшәүче халык тормышын чагылдыручы мәгълүматлар бар Алар ел саен мөһим тарихи һәм гамәли әһәмияткә ия булган документлар белән тулылана.

Электрон документ әйләнеше үсеше һәм оешмаларның эш башкару практикасында электрон документлар санын арттыру Татарстан Республикасы Архив фонды составын объектив рәвештә төр ягыннан эзлекле үзгәрешкә китерергә тиеш. Шуңа күрә муниципаль архивны электрон документларны кабул итүгә, саклауга һәм куллануга әзерләү, аларның аутентиклыгын (төп нөсхәгә тулысынча туры килә торган булуын) тәэмин итү – архив эшен үстерүнең өстенлекле юнәлеше.

Комплектлау чыганакларының составы яңадан каралды һәм киңәйтелде, шартнамә нигезендә дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм шәхси фонд хуҗалары белән хезмәттәшлеккә аерым игътибар бирелде.

Муниципаль архивны туплауда ел саен оешмаларда – комплектлау чыганакларында барлыкка килә торган даими саклау документлары күләменең артуы күзәтелә, шулай ук ябылган оешмаларның шәхси составы буенча кабул ителә торган документлар күләме дә арта.

2016 елда Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге архив документларын Озак вакытка саклау өчен архив учреждениеләренә куелган таләпләргә тулысынча туры килгән биналарга күчерелде. Кукмара муниципаль архивында иркен эш кабинетлары, клиентлар өчен урыннар, архив саклау урыннары бар.

Алга таба янгын һәм сакчылык куркынычсызлыгын ныгыту, муниципаль архивта температура-дымлылык режимын үтәү таләп ителә.

Сакланышны тәэмин итү чаралары системасында, архив документларын картонлаштыру өчен махсус чаралар кулланып, документларны картонлаштыру, тәрәзәләренә тимер рәшәткәләр урнаштыру аерым урын алып тора.

Бердәм мәгълүмати-аналитик системаны булдыру муниципаль архивның ачыклыгын сизелерлек арттыруга, заманча мәгълүмати технологияләрне куллану нигезендә архив документларын кулланунның үтемлелеген һәм нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк, профильле функцияләрнең үтәлешен оптимальләштерергә һәм архив фондларын исәпкә алу, саклау һәм идарә итүне яңа сыйфат дәрәҗәсенә чыгарырга китерәчәк.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль архивы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм үтемлелеген арттыру, шул исәптән электрон рәвештә хезмәт күрсәтүгә күчү – 2018 – 2020 елларга өстенлекле бурыч.

Дәүләт структуралары өчен архив – идарә итү документларын саклау һәм документлар белән идарә итү системасында экспертлар.

Фәнни җәмәгатьчелек вәкилләрен темаларның иң киң спектры һәм иң киң хронология кызыксындыра. Архивчылар һәм галим-гуманитарийлар арасында архив документларын өйрәнү, бастырып чыгару һәм экспонирование, кадрлар әзерләү өлкәсендә традицион рәвештә тыгыз хезмәттәшлек бар.

Безнең документаль мирасны өйрәнү һәм популярлаштыру өлкәсендә тикшеренүчеләр белән хезмәттәшлекне үстерергә кирәк.

Бу тема Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында» 2016 елның 11 гыйнварындагы УП-1 номерлы Указын гамәлгә ашыру контекстында аеруча актуаль.

Кукмара муниципаль районы муниципаль архивында ел саен Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә багышланган Батырлык дәресләре, дәрес-экскурсияләр, дәрес-күргәзмәләр үткәрелә. Чын документлар белән танышу һәрвакыт укучыларда зур тәэсир калдыра.

Фәнни җәмәгатьчелек белән хезмәттәшлек итүдә фәнни һәм тарихи-мәдәни әһәмияткә ия булган документларның сакланышын һәм сыйфатлы туплануын тәэмин итү өстенлекле бурыч булып тора. Бу эштә, аның үтемлелеген арттыру максатларында, документаль мирасны цифрлаштыру мөһим әһәмияткә ия.

## 3. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны тормышка ашыру анда игълан ителгән чаралар нигезендә гамәлгә ашырыла һәм Программаны тормышка ашыру буенча ел саен план төзүне, төгәлләштерелгән эш планнарын төзүне күздә тота.

Программаның өстенлекле юнәлешләре:
мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру;
мәдәни-ял итү эшчәнлеге өлкәсен үстерү;
хезмәткәрләр һәм укучылар өчен компьютерлаштырылган эш урыннары булдыру;
мультимедиа материаллар фондын үстерү;
фондның бер өлешен электрон рәвешкә күчерү;
үзәкләштерелгән мәгълүмат базаларын куллану;
уку абруен һәм аның иҗтимагый әһәмиятен саклап калуга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;
китапны пропагандалауга бәйле кампанияләрне оештыру һәм үткәрү;
«Хокукый мәгълүмат үзәге» эшчәнлеге;
төрле реклама продукциясе булдыру;
укучылар белән турыдан-туры элемтә (Интернет),
укуны алга этәрү буенча уртак эш алып бару өчен яңа партнерлар җәлеп итү;
өстәмә түләүле хезмәтләр күрсәтү;
хезмәткәрләрне уку һәм китапны алга этәрү буенча иң яңа методикаларга өйрәтү;
техник тәэмин ителеш;
тикшеренү эшчәнлеге;
район территориясенең йөзен (имидж) формалаштыру.

## 4. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру мәдәният өлкәсенә районның социаль һәм икътисади үсешенең реаль ресурсларыннан берсе булырга мөмкинлек бирәчәк. Конкурентлыкка сәләтле мәдәни продуктлар һәм хезмәт күрсәтүләр булдыру, аларның ассортиментын киңәйтү районда яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә, кулланучылар базарын тулыландыруга ярдәм итәчәк.

Мәдәният белән идарә итү өлкәсен модернизацияләү мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга китерәчәк.

Заманча технологияләрне куллану халыкның мәдәни кыйммәтләргә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген арттырачак.

Яңадан булдырыла торган мәдәни вакыйгалар һәм продуктлар район территориясен алга җибәрү өчен нигез була алачаклар.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге түбәндәге критерийлар белән бәяләнәчәк:
- мәдәният учреждениеләренең ремонтланган биналары саны;
- мәдәният учреждениеләрен җиһазландыру өчен техника берәмлеге саны;
- бәйрәмнәргә, концертларга, фестивальләргә йөрүче райондашлар саны;
- төрле конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашучы иҗат коллективлары өлеше;

-районнан читтә гастроль-күргәзмә эшчәнлеге күләме;
-квалификация күтәрү буенча курслар һәм тренинглар узган белгечләр саны;
-«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ҮКСы» МБУ фондларына ел саен периодик басмалар керү
- «Кукмара муниципаль районы ҮКСы» МБУнең китап фондын ел саен яңарту;
- «Кукмара муниципаль районы Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе фондларына керемнәр һәм экспонатларны саклау күләме;
- музей хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм аларның интеллектуаль дәрәҗәсен даими күтәрү.
- фәнни-тикшеренү, фәнни-методик эшчәнлекне үстерү.
- экспозиция-күргәзмә эшчәнлеген камилләштерү.
- халыкның барлык катламнарыннан килүчеләрне җәлеп итү.

Кукмара муниципаль районының тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм нәтиҗәле файдалану, аны социаль-мәдәни эшчәнлеккә тарту.

Мәдәният өлкәсе инфраструктурасын үстерү. Учреждениенең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Район халкының төрле катламнары арасында халык иҗаты традицияләрен алга этәрү буенча заманча таләпләргә җавап бирә торган мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген оештыру өчен шартлар тудыру.

Районның социаль-икътисадый үсеше ресурсы буларак үзенчәлекле гаилә традицияләрен саклау, үстерү һәм формалаштыру. Гаилә иҗатын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.

Гражданнарга гражданлык-патриотик тәрбия бирүгә юнәлтелгән традицион район чаралары системасын саклап калу һәм үстерү.

Яшьләрнең һөнәри абруен саклап калуга, һөнәри үзбилгеләнешенә ярдәм итә торган чараларны оештыру һәм уздыру

Мәдәният өлкәсендә кадрлар потенциалын саклап калу һәм яңарту.

Район территориясенең йөзен (имидж) формалаштыру. Конкурентлыкка сәләтле мәдәни продуктлар һәм хезмәтләр булдыру һәм алга этәрү. Район территориясен алга җибәрү.

Муниципаль архивта саклана торган Татарстан Республикасы Архив фонды документлары Кукмара районы гражданнарының 1930 елдан алып бүгенге көнгә кадәр булган матди һәм рухи тормышын чагылдыра һәм Кукмара районы халыкларының тарихи-мәдәни мирасының, мәгълүмати һәм интеллектуаль байлыгының мөһим өлеше булып тора.

Программа Кукмара муниципаль районы муниципаль архивы эшчәнлегенең стратегик максатына ирешүгә (Татарстан Республикасы Архив фонды һәм башка архив документларын гражданнар, җәмгыять, дәүләт мәнфәгатьләрендә саклауны, исәпкә алуны, туплауны һәм куллануны тәэмин итү) юнәлдерелгән.

Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

документлар саклау өчен оптималь шартлар булдырырга;

муниципаль, дәүләт хезмәтләренең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру, архив документларындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген киңәйтү.

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында музей эшен үстерү»
муниципаль Программасына
1 нче кушымта

**РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ**
**ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ**

| № т/н | Ярдәмче программаның исеме | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | «2018 – 2020 елларга музей эшен үстерү» | Муниципаль бюджет | 4 823,3 | 4 500,5 | 3 805,2 |
| 2 | Халык иҗатына ярдәм итү.» «2018 – 2020 елларга Кукмара районы халыкларының мәдәни мирасын саклау, торгызу һәм популярлаштыру | Муниципаль бюджет | 105 133,4 | 113 017,2 | 106 445,4 |
| 3 | «2018 – 2020 елларга китапханә эшен үстерү» | Муниципаль бюджет | 29 186,4 | 33 839,5 | 25 706,5 |
| 4 | «2018-2020 елларга архив эшен үстерү» | Муниципаль бюджет | 1 140,3 | 992,6 | 673,0 |
| | **Программа буенча барлыгы** | **429 263,3** | **140 283,4** | **152 349,8** | **136 630,1** |

## «2018-2020 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы

**Ярдәмче программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга музей эшен үстерү» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның төп эшләүчесе | «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе |
| Ярдәмче программаның максаты | Мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру.<br>Кукмара туган якны өйрәнү музее фондларын тулыландыру (архив материаллары, фәнни-тарихи ядкарьләр, сәнгать кыйммәтләре, этнографик, топонимик һәм фольклор материаллар җыю буенча экспедицияләр үткәрү). |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның бурычы | Музей, экскурсия, ял эшчәнлегенең заманча формаларын үстерү.<br>Күргәзмә эшчәнлеген киңәйтү, башка музейлар белән экспозицияләр алмашу.<br>Төрле социаль-яшь һәм белем бирү төркемнәренең мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, халыкка музей хезмәте күрсәтүне оештыру.<br>Музей ишегалдын төзекләндерү.<br>Кукмара шәһәре һәм Кукмара районының тарихи-мәдәни саклау зоналары проектларын эшләү.<br>Кукмара муниципаль районы тарих һәм мәдәният күчемсез һәйкәлләрен реставрацияләү һәм реконструкцияләү:<br>Танькино авылындагы Петропавловск чиркәве (1811 – 1822), сәүдәгәр Үтәмишевлар йорты, Мәчкәрә авылындагы беренче Собор мәчете, Мәчкәрә авылындагы икенче Собор мәчете, Түбән Өскебаш авылында Геройлар Аллеясы.<br>Музей экспонатларын: Володиннар предприятиесе эшләнмәләрен, фабрикантлар Комаров һәм Родигиннар җиһазларын реставрацияләү.<br>Татарстан Республикасы музейларының берләштерелгән электрон каталогында һәм Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогында музей предметларын теркәү.<br>Кукмара районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан экспозицияне яңарту һәм өстәмә.<br>Казан шәһәрендә Сабантуй бәйрәмендә «Татар халкының көнкүреше» экспозициясен төзү.<br>Язучының 90 еллыгына багышланган «Ч.Айтматов – даһи якташыбыз» чарасын үткәрүгә әзерлек.<br>Ч.Айтматовның «Ишмән шәҗәрәсе»нә багышланган экспозицияне яңарту. (Ч. Айтматовның әнисе линиясе буенча шәҗәрәсе). Мәчкәрә авылында Ишман шәҗәрәсе чыганагына экскурсия маршрутын эшләү. «Хәмзә Габделвәлиевнең нәсел тармагы» экспозициясен төзү.<br>Район һәм Кукмара мәктәпләренә «Чыңгыз Айтматов – даһи якташыбыз» темасына презентация белән күчмә лекцияләр.<br>Кукмара районында туып-үскән танылган шәхесләрнең юбилей даталарына һәм Кукмара районы предприятиеләре төзелүнең юбилей даталарына багышланган бәйрәм чаралары һәм күргәзмәләр үткәрү. |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләмнәре | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме<br>13 129,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 ел – 4 823,3 мең сум;<br>2019 ел – 4 500,5 мең сум;<br>2020 ел – 3 805,2 тмең сум;<br>Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен анықланырга тиеш. |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре – (елларга бүленгән нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Музей фондларын тулыландыру, тарихи һәм мәдәни мирасны саклау.<br>Тарих һәм архитектура һәйкәлләрен саклау.<br>Тарихи мирасның сакланышын контрольдә тоту.<br>Татарстан Республикасы музейларының берләштерелгән электрон каталогында һәм Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогында музей предметларын теркәү.<br>Милли мәдәниятне саклау һәм үстерү. |

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сферасының гомуми характеристикасы, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

Кукмара туган якны өйрәнү музее 1995 елның 8 маенда хакимият башлыгының 1995 елның 10 гыйнварындагы боерыгы нигезендә ачыла. Музей бертуган Родигиннар ширкәтенең элеккеге киез итек фабрикасы бинасында урнашкан. 1997 елда бина архитектура һәйкәлләре реестрына кертелгән, 1998 елда ТР Мәдәният министрлыгының «Мирас – Наследие» программасы буенча 2000 елга ТР буенча архитектура һәйкәлләрен реставрацияләү эшләре планына кертелгән.

«Мирас – Наследие» программасы эшләгән чорда музей бинасы тулысынча реставрацияләнде, һәм 2010 елның декабрендә Кукмара районы оешуга 80 ел тулу уңаеннан аны ачу тантанасы булды.

Реставрация эшләре тәмамланганнан соң музейның гомуми мәйданы 485 кв. м тәшкил итә.

Музейның төп фондын 5224 экспонат тәшкил итә, ә фәнни-ярдәмче фонд – 2126. Барлыгы: 7350 саклау берәмлеге.

Хисап елында музейда 98 экскурсия үткәрелде (аларның 72 се –төркемле, 26 сы – шәхси).

Ел дәвамында Туеш бакыр кою заводына караган рудникларның, шахталарның кайда урнашуын өйрәнү буенча тикшеренү экспедицияләре дәвам итте. Экспонатлар табу һәм җыю буенча экспедицияләр берничә тапкыр оештырылды.

Шул ук вакытта, билгеле бер казанышларга карамастан, кайбер проблемалар хәл ителмәгән булып кала бирә.

Барыннан да элек, матди-техник база көчле булмау, экспозицияләр төзү һәм экспонатларны саклау өчен мәйдан җитмәү.

## II. Ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары, ахыргы нәтиҗәләрне һәм аны гамәлгә ашыру вакытын тасвирлау

Ярдәмче программаның максаты – мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру.

Кукмара туган якны өйрәнү музее фондларын тулыландыру (архив материаллары, фәнни-тарихи ядкарьләр, сәнгать кыйммәтләре, этнографик, топонимик һәм фольклор материаллар җыю буенча экспедицияләр үткәрү).

Ярдәмче программаның максаты – музей, экскурсия хезмәте күрсәтү, ял эшчәнлегенең заманча формаларын үстерү, күргәзмә эшчәнлеген киңәйтү, башка музейлар белән экспозицияләр алмашу, төрле социаль-яшь һәм белем бирү төркемнәренең мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, халыкка музей хезмәте күрсәтүне оештыру, музей ишегалдын төзекләндерү, Кукмара шәһәренең һәм Кукмара районының тарихи-мәдәни саклау зоналары проектларын эшләү, Кукмара муниципаль районының күчемсез тарихи һәм мәдәни ядкярләрен реставрацияләү һәм реконструкцияләү: Танькино авылындагы Петропавловск чиркәве (1811 – 1822), сәүдәгәр Үтәмишевлар йорты, Мәчкәрә авылындагы беренче Собор мәчете, Мәчкәрә авылындагы икенче Собор мәчете, Түбән Өскебаш авылында Геройлар Аллеясы, музей экспонатларын реставрацияләү: Җигүле транспорт, Володиннар предприятиесе эшләнмәләре, фабрикант Комаров фабрикасы җиһазлары, Татарстан Республикасы музейларының берләштерелгән электрон каталогында һәм Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогында музей предметларын теркәү. Кукмара районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан экспозицияне яңарту.

Казан шәһәрендә Сабантуй бәйрәмендә «Татар халкының көнкүреше» экспозициясен төзү.

Язучының 90 еллыгына багышланган «Ч.Айтматов – даһи якташыбыз» чарасын үткәрүгә әзерлек. Ч.Айтматовның «Ишмән шәҗәрәсе»нә багышланган экспозицияне яңарту. (Ч. Айтматовның әнисе линиясе буенча шәҗәрәсе). Мәчкәрә авылында Ишман шәҗәрәсе чыганагына экскурсия маршрутын эшләү. «Хәмзә Габделвәлиевнең нәсел тармагы» экспозициясен төзү. Район һәм Кукмара

мәктәпләренә «Чыңгыз Айтматов – даһи якташыбыз» темасына презентация белән күчмә лекцияләр.

Кукмара районында туып-үскән танылган шәхесләрнең юбилей даталарына һәм Кукмара районы предприятиеләре төзелүнең юбилей даталарына багышланган бәйрәм чаралары һәм күргәзмәләр үткәрү.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты – 2018 – 2020 еллар.

Ярдәмче программаның көтелгән соңгы нәтиҗәсе – музей фондларын тулыландыру, тарихи һәм мәдәни мирасны саклау, тарихи һәм архитектура һәйкәлләрен саклау, тарихи мирасның сакланышын контрольдә тоту, Татарстан Республикасының берләштерелгән каталогында һәм Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогында музей предметларын теркәү, милли мәдәниятне саклау һәм үстерү.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме

13 129 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2018 ел – 4 823,3 мең сум;

2019 ел – 4 500,5 мең сум;

2020 ел – 3 805,2 мең сум;

Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен ачыкланырга тиеш.

## IV. Ярдәмче программаларның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны тормышка ашыру хезмәтләрнең конкурентлылык сәләтен булдырырга мөмкинлек бирәчәк, аларның ассортиментын киңәйтү район халкының тормыш сыйфатын күтәрүгә, хезмәт күрсәтүләрнең кулланучылар базарын тулыландыруга ярдәм итәчәк.

Тармакны модернизацияләү музей эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга китерәчәк.

Заманча технологияләрне куллану халыкның мәдәни кыйммәтләргә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген арттырачак.

Яңадан булдырыла торган мәдәни вакыйгалар һәм продуктлар район территориясен алга җибәрү өчен нигез була алачаклар.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге түбәндәге критерийлар белән бәяләнәчәк:

- «Кукмара муниципаль районы Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе фондларына керемнәр һәм экспонатларны саклау күләме;
- музей хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм аларның интеллектуаль дәрәҗәсен даими күтәрү.
- фәнни-тикшеренү, фәнни-методик эшчәнлекне үстерү.
- экспозиция-күргәзмә эшчәнлеген камилләштерү.
- халыкның барлык катламнарыннан килүчеләрне җәлеп итү.

Кукмара муниципаль районының тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм нәтиҗәле файдалану, аны социаль-мәдәни эшчәнлеккә тарту.

Ярдәмче программага
кушымта

**«2018 – 2020 ЕЛЛАРГА МУЗЕЙ ЭШЕН ҮСТЕРҮ» ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫ**
**ЧАРАЛАРЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫҺӘМ ФИНАНСЛАУ**

| № т/б | Чара исеме | Башкару | Үтәү вакыты | Финанслау чыганагы | Чараны гамәлгә ашыруга чыгымнар (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | | | | | 2018 | 2019 | 2020 |
| **I.** | **Мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру.** | | | | | | | |
| **1.1.** | **Мәдәният өлкәсе инфраструктурасын үстерү** | | | | | | | |
| 1.1.1. | Учреждениеләрнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | музей | | МБ, ВБ | - | | | |
| 1.1.2. | КАМИС комплексы автоматлаштырылган музей мәгълүмат системасы белән эшләү | музей | 2018 – 2020 еллар | РБ, МБ, ВБ | 105,0 | 35,0 | 35,0 | 35,0 |
| 1.1.3. | Халык иҗаты традицияләрен һәм район мәдәни традицияләрен алга этәрү буенча мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген оештыру өчен шартлар тудыру. | музей | | МБ, ВБ | | | | |
| 1.2. | **Мәдәният өлкәсендә кадрлар потенциалын саклап калу һәм яңарту** | | | | | | | |
| 1.2.1. | Музей белгечләренең квалификациясен күтәрү | музей | 2018 – 2020 еллар | МБ | 15 | 5 | 5 | 5 |
| 1.3 | **Гражданнарның район музей фондларының мәдәни һәм мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү** | | | | | | | |
| 1.3.1 | Медиатека булдыру һәм аның белән эш (видео-, слайд -, фоно -, аудио-фондлар) | музей | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | - | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3.2 | Бәйрәм чаралары һәм күргәзмәләр үткәрү: | музей | | | - | | | |
| 1.3.3 | Кукмара муниципаль районының 90 еллыгы; | музей | 2020 | МБ | 1 | | | 1 |
| 1.3.4 | Туган якны өйрәнү музееның 25 еллыгы; | музей | 2020 | ВБ | 1 | | | 1 |
| 1.3.11 | 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгы<br>Рәссам М. Усмановның «Дөнья фронтовик күзлегеннән» дип исемләнгән күргәзмәсен оештыру.<br>147 укчы дивизиясе оешуга 80 ел тулуга багышланган күргәзмә. | музей | 2020 | МБ, ВБ | 3 | | | 3 |
| 1.3.12 | Кукмара районының күренекле кешеләре юбилей даталарына багышланган күргәзмәләр: | музей | | | | | | |
| | Татарстан Республикасында язучы Л.Н. Толстой елы кысаларында «Лев билгесе астында» темасына лекцияләр үткәрү | музей | 2018 | МБ, ВБ | | | | |
| | Кукмара районында Ш. Мәрҗани елы кысаларында «Татар халкының мәгърифәтчесе» лекцияләрен үткәрү | музей | 2018 | МБ,ВБ | | | | |
| 1.3.13 | КПССның Беренче секретаре А.М. Булатовка 90 ел (түгәрәк өстәл, туганнары белән очрашу) | музей | 2018 | МБ, ВБ | 0,5 | 0,5 | | |
| 1.3.14 | Советлар Союзы Герое П.Е. Воробьевның тууына 110 ел | музей | 2018 | МБ,ВБ | 0,5 | 0,5 | | |
| 1.3.15 | Н.И. Идрисовның тууына 100 ел | музей | 2018 | МБ,ВБ | 0,5 | 0,5 | | |
| 1.3.16 | ТАССРның халык рәссамы, атказанган мәдәният хезмәткәре М.Г. Усмановның тууына 100 ел | музей | 2018 | МБ,ВБ | 0,5 | 0,5 | | |
| 1.3.17 | Җырчы, РСФСРның атказанган артисты А.С. Фадеичевага 75 яшь (юбиляр белән очрашу) | музей | 2018 | МБ,ВБ | 0,5 | 0,5 | | |
| 1.3.18 | Язучы Ч.Т. Айтматовның тууына 90 ел | музей | 2018 | МБ,ВБ | 0,5 | 0,5 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3.19 | Композитор М. Х. Яхинның тууына 105 ел | музей | 2019 | МБ,ВБ | 0,5 | | 0,5 | |
| 1.3.20 | Советлар Союзы Герое И.Г. Газизуллинның тууына 100 ел | музей | 2019 | МБ,ВБ | 0,5 | | 0,5 | |
| 1.3.11 | Композитор Ф. А. Әхмәтовның тууына 85 ел | музей | 2020 | МБ,ВБ | 0,5 | | | 0,5 |
| 1.3.22 | Шагыйрь Р. Ш. Шәриповның тууына 70 ел | музей | 2020 | МБ,ВБ | 0,5 | | | 0,5 |
| 1.3.23 | Рәссам М. Х. Исмәгыйлевның тууына 70 ел (юбиляр белән очрашу) | музей | 2020 | МБ,ВБ | 0,5 | | | 0,5 |
| 1.3.24 | Советлар Союзы Герое Н.С. Савинның тууына 105 ел | музей | 2020 | МБ,ВБ | 0,5 | | | 0,5 |
| 1.3.29 | Мәгълүмати буклетлар чыгару | музей | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | | | | |
| 1.3.31 | Казан шәһәрендә Сабантуй бәйрәмендә «Татар халкының көнкүреше» экспозициясен төзү. | музей | 2018 – 2020 | РБ | 90 | 30 | 30 | 30 |
| 1.4 | **Районны бердәм мәгълүмати һәм мәдәни киңлеккә (пространство) кертү** | | | | | | | |
| 1.4.1 | Музейның WEB-сайтын даими яңарту | музей | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | | | | |
| 1.5 | **Финанс-хуҗалык эшчәнлеге** | | 2018 – 2020 | | | | | |
| 1.5.1 | Учреждениенең хезмәт хакы фонды | музей | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 8898,9 | 3113,4 | 3121,1 | 2664,4 |
| 1.5.2 | Хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү буенча мәҗбүри социаль иминият взнослары һәм учреждениеләр хезмәткәрләренә башка түләүләр | музей | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 2684,1 | 936,9 | 942,6 | 804,6 |
| 1.5. 3 | Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу | музей | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 1489,8 | 751,0 | 424,9 | 313,9 |
| 1.5.4 | Салым һәм җыемнар түләү | музей | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 56,2 | 22,0 | 11,9 | 22,3 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | | | | **13350,0** | **4896,3** | **4571,5** | **3882,2** |

## «2018 – 2020 елларга Кукмара районы халыкларының мәдәни мирасын саклау, торгызу һәм популярлаштыру. Халык иҗатына ярдәм итү» Ярдәмче программасы

### Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара районы халыкларының мәдәни мирасын саклау, торгызу һәм популярлаштыру. Халык иҗатына ярдәм итү» (алга таба – Ярдәмче программа ) |
| Ярдәмче программаның төп эшләүчесе | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Мәдәният үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе |
| Ярдәмче программаның максаты | Мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру.<br>Мәдәни-ял итү эшчәнлеге өлкәсен үстерү.<br>Район территориясенең йөзен (имидж) формалаштыру. |
| Ярдәмче программаның бурычы | Район халкының төрле катламнары арасында халык иҗаты традицияләрен алга этәрү һәм заманча таләпләргә җавап бирә торган үзешчән иҗатны гамәлгә ашыру буенча мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген оештыру өчен шартлар тудыру;<br>Традицион халык мәдәниятенә, үзешчән сәнгати иҗатка һәм һөнәри сәнгатькә ярдәм итү;<br>Традицион район чаралары системасын саклау һәм үстерү. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләмнәре | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме<br>324 596,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 ел – 105 133,4 мең сум;<br>2019 ел – 113 017,2 мең сум;<br>2020 ел – 106 445,4 мең сум.<br>Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен анykланырга |

| | |
|---|---|
| | тиеш |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре – (елларга бүленгән нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Мәдәни хезмәтләр ассортиментын киңәйтү. Мәдәни чараларның һәм хезмәтләрнең файдалану мөмкинлеген арттыру. Халыкның күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсен күтәрү.<br>Шәхси, иҗади, мәдәни һәм интеллектуаль потенциалларын гамәлгә ашыру буенча халык өчен мөмкинлекләрне киңәйтү.<br>Яшь буында гражданлык хисләре барлыкка килүенә йогынты һәм тулаем алганда, районның барлык торак пунктларында да уңайлы социаль мохит булдыруга йогынты ясау;<br>Мәдәният өлкәсе белгечләренең һөнәри компетентлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.<br>Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту.<br>Мәдәният учреждениеләре җиһазларын модернизацияләү.<br>Мәдәният учреждениеләрен эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итү. |

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сферасының гомуми характеристикасы, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

«2018 – 2020 елларга Кукмара районы халыкларының мәдәни мирасын саклау, торгызу һәм популярлаштыру. Халык иҗатына ярдәм итү» программасы Кукмара муниципаль районы халкының мәдәни үсеше ярдәмче программасы максатларын һәм бурычларын, мәдәни-ял эшчәнлеген модернизацияләү буенча документларны үтәүне, халыкның мәдәният хезмәтләре күрсәтүгә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү һәм әлеге системаның киләчәктә камилләшүен исәпкә алып эшләнгән.

Программа Татарстан Республикасы Кукмара районында мәдәни-ял итү эшчәнлеген үстерүнең кыйммәтле-мәгънәле максатчан, эчтәлекле һәм нәтиҗәле өстенлекләрен билгели, үзгәрешләрнең төп алымнарын һәм механизмнарын бирә.

Кукмара муниципаль районында 123 торак пункт бар, аларда 51 114 кеше яши (Кукмара шәһәрендә 17 700 кеше). Аларга 79 мәдәният учреждениесе (78 – КДУ, 1 автоклуб) хезмәт күрсәтә.

Кукмара муниципаль районы КДУның эш системасы торышы уңай нәтиҗәләр белән характерлана.

Халыкка мәдәни белем бирүнең күп вариантлы челтәре булдырылган.

Район мәдәният йорты һәм авыл мәдәният йорты базасында мәдәни эшчәнлек актив үсә.

Мәдәни-ял итү эшчәнлегенең эчтәлеген, халыкның үзгәреп торучы запрослары нигезендә формаларны һәм технологияләрне яңарту, хезмәтләрнең

барлык өлкәләрен модернизацияләү концепциясен тормышка ашыру процессы бара.

Программа-методик һәм мәгълүмати тәэмин итүне камилләштерү гамәлгә ашырыла. Методик хезмәтләр (методик берләшмәләр, өйрәтү семинарлары) тотрыклы эшли.

Кадрлар белән эшләү сыйфат ягыннан яхшырды.

Мәдәни ял итү эшчәнлегенең үсеш дәрәҗәсен билгеләүче төп факторлар:

- Кукмара муниципаль районы хакимияте тарафыннан игътибар һәм кайгырту;
- норматив-хокукый базаны камилләштерү;
- ведомствоара хезмәттәшлек – балалар һәм олылар иҗатын тәрбияләүнең төрле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советлары комиссияләре эшчәнлеге;
- башка районнар белән традицион мәдәниятара элемтәләрне ныгыту һәм үстерү.

## II. Ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары, ахыргы нәтиҗәләрне һәм аны гамәлгә ашыру вакытын тасвирлау

Ярдәмче программаның максаты – мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру.

Мәдәни-ял итү эшчәнлеге өлкәсен үстерү. Район территориясенең йөзен (имидж) формалаштыру.

Ярдәмче программаның максаты – район халкының төрле катламнары арасында халык иҗаты традицияләрен алга этәрү һәм үзешчән иҗатны гамәлгә ашыру буенча мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген оештыру өчен шартлар тудыру; традицион халык мәдәниятен, үзешчән сәнгатьне һәм һөнәри сәнгатьне үстерү; традицион район чаралары системасын саклау һәм үстерү.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты – 2018 – 2020 еллар.

Ярдәмче программаның көтелгән соңгы нәтиҗәсе – мәдәният хезмәтләренең ассортиментын киңәйтү, мәдәни чараларның һәм хезмәтләрнең үтемлелеген арттыру, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатыннан халыкның канәгатьлек дәрәҗәсен күтәрү, шәхси, иҗади, мәдәни һәм интеллектуаль потенциалларын гамәлгә ашыру буенча халык өчен мөмкинлекләрне киңәйтү, яшь буынның гражданлык хәленә һәм тулаем районның барлык торак пунктларында уңай социаль мохит булдыруга йогынты ясау, мәдәният өлкәсе белгечләренең һөнәри компетентлыгын арттыру өчен шартлар тудыру, мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту, мәдәният учреждениеләре җиһазларын модернизацияләү, мәдәният учреждениеләрен эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итү.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме

324 596,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:
2018 ел – 105 133,4 мең сум;
2019 ел – 113 017,2 мең сум;
2020 ел – 106 445,4 мең сум;
Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме алдан фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

## IV. Ярдәмче программаларның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны тормышка ашыру мәдәният өлкәсенә районның социаль һәм икътисади үсешенең реаль ресурсларыннан берсе булырга мөмкинлек бирәчәк. Конкурентлыкка сәләтле мәдәни продуктлар һәм хезмәт күрсәтүләр булдыру, аларның ассортиментын киңәйтү районда яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә, кулланучылар базарын тулыландыруга ярдәм итәчәк.

Мәдәният өлкәсен модернизацияләү мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга китерәчәк.

Заманча технологияләрне куллану халыкның мәдәни кыйммәтләргә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген арттырачак.

Яңадан булдырыла торган мәдәни вакыйгалар һәм продуктлар район территориясен алга җибәрү өчен нигез була алачаклар.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге түбәндәге критерийлар белән бәяләнәчәк:

- мәдәният учреждениеләренең ремонтланган биналары саны;
- мәдәният учреждениеләрен җиһазландыру өчен техника берәмлеге саны;
- бәйрәмнәргә, концертларга, фестивальләргә йөрүче райондашлар саны;
- төрле конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашучы иҗат коллективлары өлеше;
-ррайоннан читтә гастроль-күргәзмә эшчәнлеге күләме;
-квалификация күтәрү буенча курслар һәм тренинглар узган белгечләр саны;

Мәдәният өлкәсе инфраструктурасын үстерү. Учреждениенең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Район халкының төрле катламнары арасында халык иҗаты традицияләрен алга этәрү буенча заманча таләпләргә җавап бирә торган мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген оештыру өчен шартлар тудыру.

Районның социаль-икътисадый үсеше ресурсы буларак үзенчәлекле гаилә традицияләрен саклау, үстерү һәм формалаштыру. Гаилә иҗатын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.

Гражданнарга гражданлык-патриотик тәрбия бирүгә юнәлтелгән традицион район чаралары системасын саклап калу һәм үстерү.

Яшьләрнең һөнәри абруен саклап калуга, һөнәри үзбилгеләнешенә ярдәм итә торган чараларны оештыру һәм уздыру

Мәдәният өлкәсендә кадрлар потенциалын саклап калу һәм яңарту.

Район территориясенең йөзен (имидж) формалаштыру.

Конкурентлыкка сәләтле мәдәни продуктлар һәм хезмәтләр булдыру һәм алга этәрү. Район территориясен алга җибәрү.

Ярдәмче программага
кушымта

**«2018-2020 ЕЛЛАРГА КУКМАРА РАЙОНЫ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫН САКЛАУ, ТОРГЫЗУ ҺӘМ ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ. ХАЛЫК ИҖАТЫНА ЯРДӘМ» ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫ ЧАРАЛАРЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ФИНАНСЛАУ**

| № т/б | Чара исеме | Башкаручы | Үтәлү вакыты | Финанслау чыганагы | Чараны гамәлгә ашыруга чыгымнар (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | | | | | 2018 | 2019 | 2020 |
| **I** | **«РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ СИСТЕМАСЫН КАМИЛЛӘШТЕРҮ** | | | | | | | |
| **1.1.** | **Мәдәният өлкәсе инфраструктурасын үстерү** | | | | | | | |
| 1.1. | «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе каршындагы мәдәни-ял итү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Сәнгать советы булдыру. | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Гыйнвар 2018 ел | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Мәдәни-ял итү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча «РДК» МБУ каршындагы Сәнгать советы утырышларын үткәрү | «РДК» МБУ каршындагы Сәнгать советы | Айга 2 тапкыр | - | - | - | - | - |
| II | **КАДРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ, ЯҢАДАН ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ КВАЛИФИКАЦИЯЛӘРЕН КҮТӘРҮ** | | | | | | | |
| 2.1 | Мәдәният учреждениеләре кадрларының квалификациясен күтәрү | МБУ «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ», ИДПО | Период дәвамында | МБ, ВБ | 60 | 20 | 20 | 20 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2 | Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре өчен фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар һәм башка укыту формалары оештыру | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | МБ | - | - | - | - |
| 2.3 | Һөнәри осталык конкурслары үткәрү | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ | - | - | - | - |
| 2.4 | Эш урыннары аттестациясен үткәрү | МБУ «РДК» эш урыннарын аттестацияләү буенча лицензия оешмасы | 5 елга бер тапкыр | МБ | - | - | - | - |
| 2.5 | Мәдәният учреждениеләре белгечләре һәм җитәкчеләренә ихтыяҗлар турында мәгълүматлар банкын булдыру буенча эш | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | - | - | - | - | - |
| 2.6 | Мәдәният учреждениеләрендә мәдәни-ял эшләрен оештыру буенча методик рекомендацияләр әзерләү һәм тарату | «Район мәдәният йорты» МБУнең методик хезмәте | Ел саен | - | - | - | - | - |
| 2.7 | Халыкның ялын оештыру өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне ачыклау, өйрәнү һәм гомумиләштерү эшен оештыру һәм башка хезмәткәрләргә җиткерү. | «Район мәдәният йорты» МБУнең методик хезмәте | даими | - | - | - | - | - |
| **III** | **МӘДӘНИЯТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНЕҢ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ҺӘМ МАТДИ-ТЕХНИК БАЗАСЫН НЫГЫТУ** | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1 | Тавыш көчәйткеч һәм ут аппаратурасы сатып алу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 480 | 150 | 160 | 170 |
| 3.2 | Мәдәният учреждениеләре өчен музыка аппаратурасы һәм инструментлар сатып алу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 480 | 150 | 160 | 170 |
| 3.3 | Мәдәният учреждениеләре өчен ноутбуклар сатып алу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 180 | 50 | 60 | 70 |
| 3.4 | Мәдәният учреждениеләре өчен театр кәнәфиләре сатып алу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 450 | 150 | 150 | 150 |
| 3.5 | Мәдәният учреждениеләрендә район мәдәният йорты бинасында автоматик янгын сигнализациясе системасын урнаштыру | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 300 | 100 | 100 | 100 |
| 3.6 | Мәдәният учреждениеләре бинасын пандуслар һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең иректе хәрәкәте өчен башка махсус төзелмәләр һәм җайланмалар белән тәэмин итү | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 150 | 50 | 50 | 50 |
| 3.2. | Сәхнә костюмнары (сәхнә өчен кием-салым һәм ансамбльләр өчен костюмнар тегү) | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 450 | 150 | 150 | 150 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.8 | Бию коллективлары өчен аяк киеме тегү һәм сатып алу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 110 | 30 | 40 | 40 |
| **IV** | **МӘДӘНИ-ЯЛ ИТҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ ӨЛКӘСЕН ҮСТЕРҮ. ГРАЖДАННАРНЫҢ МӘДӘНИ ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ РЕСУРСЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ МӨМКИНЛЕГЕН ТӘЭМИН ИТҮ** | | | | | | | |
| 4.1 | Халыкның мәдәни-ял итү эшчәнлеге мәсьәләләрен өйрәнү, анализлау һәм хәл итүне тәэмин итү | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | даими | - | - | - | - | - |
| 4. | Кукмара районы Халык сәнгать промыселлары һәм һөнәрчелеге осталарының мәгълүматлар базасын булдыру | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | даими | - | - | - | - | - |
| 4.3 | Барлык клуб учреждениеләрендә түгәрәкләр эшен, төрле юнәлештәге мәдәни-ял формированиеләрен оештыру (театр, вокал, инструменталь, хореография һ. б.) | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | - | - | - | - | - |
| 4.4 | Район территориясендә фольклор экспедицияләре үткәрү | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Аерым план буенча | - | - | - | - | - |
| 4.5 | «Һәркемгә дә уңайлы мәдәният» стационар мәдәният учреждениеләре булмаган торак пунктларда яшәүчеләрнең ялын оештыру | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | даими | МБ, ВБ | 90 | 30 | 30 | 30 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.6 | Мәдәният министрлыгының уку йортларына кергәндә талантлы балаларга – мәдәният учреждениеләренең иҗат коллективларында катнашучыларына ярдәм итү | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Даими | - | - | - | - | - |
| **V** | **МАССАКҮЛӘМ МӘДӘНИ-ЯЛ ЧАРАЛАРЫН ОЕШТЫРУ** | | | | | | | |
| 5.1 | «Күңелле Раштуа» рус фольклор бәйрәме | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |
| 5.2 | Иске Яңа елны каршы алу театральләштерелгән бәйрәме | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 90 | 30 | 30 | 30 |
| 5.3 | «Кукмара кышы» Татар җыры район фестиваль-конкурсы | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 90 | 30 | 30 | 30 |
| 5.4 | Балалар театр коллективларының район смотр-конкурсы | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 21 | 7 | 7 | 7 |
| 5.5 | Авыл җирлекләре арасында район фестиваль-конкурсы | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 150 | 50 | 50 | 50 |
| 5.6 | Хәрби-патриотик җырлар һәм нәфис сүз буенча традицион район смотр-конкурсы | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 15 | 5 | 5 | 5 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.7 | Ватанны саклаучылар көне кысаларында хәрби-патриотик җырлар, нәфис сүз һәм сәнгать смотр-конкурсы лауреатларының Гала-концерты | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 15 | 5 | 5 | 5 |
| 5.8 | Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган тантаналы кичә | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |
| 5.9 | «Ел хатын-кызы» республика конкурсында катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 45 | 15 | 15 | 15 |
| 5.10 | «Нәүрүз» Кыш озату театрлаштырылган бәйрәмен үткәрү | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 15 | 5 | 5 | 5 |
| 5.11 | "Минем һөнәрем – кешеләргә шатлык бүләк итү» – иң яхшы клуб хезмәткәрләренә һәм үзешчән сәнгать коллективларына багышланган тематик кичә | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 45 | 15 | 15 | 15 |
| 5.12 | «Иделкәй» театр коллективларының республика конкурсында катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 24 | 8 | 8 | 8 |
| 5.13 | «Шома бас» район биюләр смотр-конкурсы | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |
| 5.14 | Район мәдәният йорты халык театры спектакле премьерасы | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 45 | 15 | 15 | 15 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.15 | Халык театрларының «Идел Йорт» зона һәм республика конкурсында катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 90 | 30 | 30 | 30 |
| 5.16 | «Уйна, гармун» Гармунчылар республика фестиваль-конкурсы» | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |
| 5.17 | Яз һәм Хезмәт бәйрәме | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |
| 5.18 | «Каравон» рус фольклоры республика бәйрәмендә катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |
| 5.19 | Җиңү көненә багышланган театральләштерелгән митинг | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 100 | 30 | 35 | 35 |
| 5.20 | «САБАНТУЙ» милли бәйрәменә театральләштерелгән пролог һәм концерт программасын әзерләү һәм оештыру | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 210 | 70 | 70 | 70 |
| 5.11 | Казан шәһәрендә «Сабантуй» Республика милли бәйрәмендә катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 600 | 200 | 200 | 200 |
| 5.2. | «Сәламәт яшәү рәвеше өчен» район акциясе кысаларында агитбригада белән «Нараткай» ял лагерена һәм башка лагерьларга бару | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 18 | 6 | 6 | 6 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.23 | «Гырон быдтон» Республика удмурт бәйрәмен уздыру | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | | МБ, ВБ | 50 | 16 | 17 | 17 |
| 5.24 | Мари мәдәниятенең «Семык» республика бәйрәмендә катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | ел саен | МБ, ВБ | 50 | 16 | 17 | 17 |
| 5.25 | «Питрау» керәшен фольклор бәйрәме | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |
| 5.26 | Наркомания һәм эчкечелекне профилактикалау буенча «Безнең белән бергә сайла» автойөреше | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 15 | 5 | 5 | 5 |
| 5.27. | Татарстан Республикасы көненә багышланган күпмилләтле халык иҗаты фестивале | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 48 | 16 | 16 | 16 |
| 5.28 | «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» район акциясе | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 15 | 5 | 5 | 5 |
| 5.29 | «Балкыш – Сияние» район смотр-конкурсын үткәрү, зона этабында катнашу һәм республика фестивале кысаларында ветераннар арасында Гала-концертта катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | ел саен | МБ, ВБ | 60 | 20 | 20 | 20 |
| 5.30 | Көзге көн белән төн тигезләшү бәйрәме «Сөмбелә» халык бәйрәме | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 30 | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.31 | Казан шәһәрендә һәм Кукмара ш. т. поселогында авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә концерт программасы белән катнашу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 9 | 3 | 3 | 3 |
| 5.32 | «Яшьлегем юллары» клубы һәм үзешчән сәнгать ветераннары катнашында тематик кичә-хатирәләр | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 15 | 5 | 5 | 5 |
| 5.33 | Әниләр көнен бәйрәм итү кысаларында әниләр турында җыр һәм шигырьләр башкаручыларның район конкурсы һәм конкурс лауреатлары һәм дипломантлары катнашында Гала – концерт | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | ел саен | МБ, ВБ | 9 | 3 | 3 | 3 |
| 5.34 | Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көне кысаларында СПИДка каршы көрәш көненә багышланган Сәламәт яшәү рәвеше өчен район марафоны | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 12 | 4 | 4 | 4 |
| 5.35 | «Каз өмәсе» театральләштерелгән фольклор бәйрәме | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 21 | 7 | 7 | 7 |
| 5.36 | Халыклар бердәмлеге көнен һәм Татарстан Республикасы Конституциясе көнен бәйрәм итү кысаларында тематик концерт . | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 36 | 12 | 12 | 12 |
| 5.37 | Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең «Мин яратам сине, тормыш!» район халык иҗаты фестивале | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 12 | 4 | 4 | 4 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.38 | Яңа ел бал-маскарады | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Ел саен | МБ, ВБ | 105 | 35 | 35 | 35 |
| **VI** | **МӘГЪЛҮМАТИ-АНАЛИТИК ҺӘМ ПРОПАГАНДА ЭШЧӘНЛЕГЕ** | | | | | | | |
| 6.2 | «Хезмәт даны» («Трудовая слава») район газетасы битләрендә районның мәдәни тормышын яктырту | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | - | - | - | - | - |
| 6.3 | Район чаралары турында мәгълүмати фото-видеоматериаллар булдыру һәм куллану | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | - | - | - | - | - |
| 4.4 | Район мәдәният учреждениеләре эше турындагы материалларны район башлыгы аппараты сайтында һәм мәдәният идарәсе сайтында җирле радиода яктырту өчен урнаштыру | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | - | - | - | - | - |
| **VII** | **ФИНАНС-ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ** | | | | | | | |
| 7.1 | Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | МБ, ВБ | 192541,4 | 62278,3 | 71079,9 | 59183,2 |
| 7.2 | Хезмәт өчен түләү хисаплау | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | МБ, ВБ | 52886,9 | 18782,5 | 16533,9 | 17570,5 |
| 7.3 | Хезмәткә түләү фондыннан тыш, казна учреждениеләре хезмәткәрләренә башка түләүләр | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | МБ | 748,4 | 345,6 | 102,8 | 300,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.4 | Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | МБ | 76680,8 | 23394,2 | 24887,2 | 28399,4 |
| 7.5 | Салым һәм җыемнар түләү | «РАЙОН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ» МБУ | Период дәвамында | МБ | 1738,5 | 332,8 | 413,4 | 992,3 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | **329616,0** | **106765,4** | **114696,2** | **108154,4** |

## «2018 – 2020 елларга китапханә эшен үстерү»
## Ярдәмче программасы

**Ярдәмче программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга китапханә эшен үстерү» (алга таба – Ярдәмче программа ) |
| Ярдәмче программаның төп эшләүчесе | «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе |
| Ярдәмче программаның максаты | Китапханәнең, китапның, укуның иҗтимагый әһәмиятле статусын, шулай ук кулланучыларның гомуми һәм мәгълүмати культура дәрәҗәсен арттыру өчен китапханәнең потенциаль мөмкинлекләрен куллану һәм нәтиҗәлелеген арттыру хисабына күтәрү өчен шартлар тудыру |
| Ярдәмче программаның бурычы | Гражданнарның район музей һәм китапханә фондларының мәдәни һәм мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү; китап укуга һәм китапханәдән файдалануга халыкның барлык категорияләрен җәлеп итү, китапханәнең абруен һәм ролен күтәрү; китапның һәм укуның, китапханәнең мәгълүмати ресурсларының бай потенциалын, ачу;<br>әдәбият турында мәгълүмат бирү системасын оптимальләштерү һәм китапханә-мәгълүмати хезмәт күрсәтүне камилләштерү; укучыларга укуны алга этәрүгә ярдәм итүче социаль әһәмиятле китап-журнал, аудиовизуаль һәм мультимедиа продукциясен бирү өчен максималь уңай шартлар тудыру; уку өлкәсендә яңа эш формалары һәм методларын апробацияләү; барлык кызыксынган затлар һәм оешмалар белән укуга ярдәм итү һәм аны алга этәрүдә хезмәттәшлек итү; мәгълүмат җыю, халыкка тапшыру һәм бирүнең яңа технологияләрен кертү; халыкка Интернетка ирекле керү мөмкинлеге бирү; мшәһәр халкын мәгълүмати җәмгыять шартларында актив эшчәнлеккә әзерләү; иҗтимагый әһәмиятле проектларны, интеллектуаль ял программаларын эшләү һәм тормышка ашыру; кирәкле матди-техник база булдыру. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләмнәре | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 88732,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 ел – 29186,4 мең сум;<br>2019 ел – 33839,5 мең сум;<br>2020 ел – 25706,5 мең сум;<br>Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен ачыкланырга тиеш |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре – (елларга бүленгән нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Китапханәнең мәгълүмати, мәдәни, агарту һәм социаль функциясен көчәйтү, китап укуга, китапка, төрле төркем кулланучыларның мәгълүмат ресурсларына мотивацияне арттыру, кулланучыларның заманча ихтыяҗларына туры килә торган көчле мәгълүмати ресурслар булдыру; шәхси, иҗади, мәдәни һәм интеллектуаль потенциалларын гамәлгә ашыру буенча халык өчен мөмкинлекләрне киңәйтү; яшь буынның гражданлыгын торгызуга һәм тулаем районның барлык торак пунктларында уңайлы социаль мохит булдыруга йогынты ясау; фондларның оптималь режимын һәм сакланышын тәэмин итү; район китапханәчеләренең квалификациясен күтәрү системасын булдыру |

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сферасының гомуми характеристикасы, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

«2018 – 2020 елларга китапханә эшен үстерү» Ярдәмче программасы Кукмара муниципаль районы халкының мәдәни үсеше ярдәмче программасы максатларын һәм бурычларын үтәү зарурлыгыннан чыгып эшләнгән.

Ярдәмче программа Татарстан Республикасы Кукмара районында китапханә эшчәнлеген үстерүнең кыйммәтле-мәгънәле максатчан, эчтәлекле һәм нәтиҗәле өстенлекләрен билгели, үзгәрешләрнең төп алымнарын һәм механизмнарын билгели.

Китапханә – ул зирәклек, аралашу гыйбадәтханәсе генә түгел. Белем һәм изгелек. Ул, барыннан да элек, һәркемгә ачык заманча мәгълүмат үзәге. Соңгы

вакытта безнең тормышта күп нәрсә үзгәрде, китап укучыларыбыз да бераз башка, кызганычка каршы, аларның китапка мөнәсәбәте үзгәрде. Мәгълүм ки, бүген аны күп очракта мәгълүмати технологияләр алмаштыра. Ашыкмыйча, уйланып китап укучылар саны кими. Тиз, мобиль кулланучылар арта бара. Әлбәттә, компьютер, Интернет һәм уку үзара ярашалар. Китапханәләрнең хәзерге шартларда эшләү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бу ярашу урынлы гына түгел, файдалы да. Хәзерге китапханә төрле категория китап укучыларының запросларына, алар теләсә нинди мәгълүматны яки теләсә кайсы сорауга җавапны аның өчен уңайлы форматта – кәгазьдә яки электрон рәвештә таба алсын өчен, туры килергә тиеш. 2018 – 2020 елларга китапханәне үстерүнең әлеге Программасы нәкъ шуны күздә тота.

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең заманча укучыга хезмәт күрсәтү өчен шактый саллы матди-техник базасы бар. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ярдәме белән 5 мобиль китапханә җиһазландырылган, 49 китапханәнең барысында да компьютерлар бар, шуларның 46 сы Интернетка тоташкан, барлык китапханәләр дә күчереп алу-күбәйтү техникасы белән җиһазландырылган.

«Кукмара муниципаль районы ҮКСы» МБУ укучылары саны 33141 кешедән артып киткән очракта, китапханәчеләр елына 1 укучыга 0,58 яңа китап, ягъни район кешесенә 0,39 китап сатып ала, үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китап фондының 70% ы мораль яктан искергән.

Шулай итеп, басма еллары буенча фонд составы Россия китапханәләр ассоциациясе тарафыннан кабул ителгән массакүләм китапханәләр эшчәнлегенең Модель стандарты тәкъдим иткән нормативларга туры килми. Моннан тыш, китапларның күбесе бердәнбер нөсхәдә керә һәм, шуның нәтиҗәсендә, укучы запросларын канәгатьләндерә алмый һәм тиз арада искерә, шул рәвешле, китап фонды составында җитешсезлекләр барлыкка килә.

Район китапханәләренең тышкы һәм эчке эшчәнлегенә анализ түбәндәгеләрне күрсәтте: үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китапханәләреннән барлык буын кешеләре даими файдаланалар. Кулланучыларның төп өлеше – балалар һәм яшьләр: мәктәп, лицей, гимназия, көллият укучылары. Кулланучыларның киләсе төркеме – халыкның социаль яктан якланмаган катламнары (пенсионерлар, инвалидлар, эшсез гражданнар), алар өчен китапханә – бушлай булган бердәнбер мәгълүмат һәм мәдәният учагы.

Шул ук вакытта, билгеле бер казанышларга карамастан, тармакта кайбер проблемалар хәл ителмәгән булып кала бирә.

Барыннан да элек, китапханәләрнең матди-техник базасы начарлыг, ә нәкъ менә:

янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә акча булмау;

биналарга капиталь һәм косметик ремонт кирәклеге;

китапханәләрдәге җиһазларның сакланышын тәэмин итү зарурилыгы (тәрәзәләрдәге рәшәткәләр, тимер ишекләр);

искергән җиһазлар;

китап фондын мультимедиа продукциясе, электрон ресурслар белән тулыландыру өчен акча җитмәү.

## II. Ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары, ахыргы нәтиҗәләрне һәм аны гамәлгә ашыру вакытын тасвирлау

Ярдәмче программаның максаты – китапханәнең, китапның, укуның иҗтимагый әһәмиятле статусын, шулай ук кулланучыларның гомуми һәм мәгълүмати культура дәрәҗәсен арттыру өчен китапханәнең потенциаль мөмкинлекләрен куллану һәм нәтиҗәлелеген арттыру хисабына күтәрү өчен шартлар тудыру.

Ярдәмче программаның максаты – гражданнарның район музей һәм китапханә фондларының мәдәни һәм мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү; барлык категория халыкны китап укуга һәм куллануга җәлеп итү, китапханәнең абруен һәм ролен күтәрү; китап һәм укуның, китапханәнең мәгълүмати ресурсларының бай потенциалын ачу; әдәбият турында мәгълүмат бирү системасын оптимальләштерү һәм китапханә-мәгълүмати хезмәт күрсәтүне камилләштерү; укучыларга укуны алга этәрүгә ярдәм итүче социаль-әһәмиятле китап-журнал, аудиовизуаль һәм мультимедиа продукциясен бирү өчен максималь уңай шартлар тудыру; уку өлкәсендә яңа эш формаларын һәм методларын апробацияләү; барлык кызыксынучы затлар һәм оешмалар белән уку-укыту эшчәнлегенә ярдәм итү һәм аны алга этәрүдә хезмәттәшлек; мәгълүмат җыю, халыкка тапшыру һәм бирүнең яңа технологияләрен кертү; халыкка Интернеттан ирекле файдалану мөмкинлеге бирү; шәһәр халкын мәгълүмати җәмгыять шартларында актив эшчәнлеккә әзерләү; иҗтимагый әһәмиятле проектларны, интеллектуаль ял итү программаларын эшләү һәм тормышка ашыру; кирәкле матди-техник база булдыру.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты – 2018 – 2020 еллар.

Ярдәмче программаның көтелгән соңгы нәтиҗәсе – китапханәнең мәгълүмати, мәдәни, агарту һәм социаль функциясен көчәйтү, китап укуга, китапка, төрле төркем кулланучыларның мәгълүмат ресурсларына мотивацияне арттыру, кулланучыларның заманча ихтыяҗларына туры килә торган көчле мәгълүмати ресурслар булдыру; шәхси, иҗади, мәдәни һәм интеллектуаль потенциалларын гамәлгә ашыру буенча халык өчен мөмкинлекләрне киңәйтү; яшь буынның гражданлыгын торгызуга һәм тулаем районның барлык торак пунктларында уңайлы социаль мохит булдыруга йогынты ясау; фондларның оптималь режимын һәм сакланышын тәэмин итү; район китапханәчеләренең квалификациясен күтәрү системасын булдыру.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме
88 732,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:
2018 ел – 29 186,4 мең сум;
2019 ел – 33 839,5 мең сум;
2020 ел – 25 706,5 мең сум.

Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен аныкланырга тиеш.

## IV. Ярдәмче программаларның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны тормышка ашыру мәдәният өлкәсенә районның социаль һәм икътисади үсешенең реаль ресурсларыннан берсе булырга мөмкинлек бирәчәк. Конкурентлыкка сәләтлелекне булдыру, аларның ассортиментын киңәйтү районда яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә, кулланучылар базарын тулыландыруга ярдәм итәчәк.

Китапханә эше тармагын модернизацияләү китапханәләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга китерәчәк.

Заманча технологияләрне куллану халыкның хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуын арттырачак.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге түбәндәге критерийлар белән бәяләнәчәк:

- китапханәләрнең ремонтланган бинаалары саны;
- китапханәләрне җиһазландыру өчен техника берәмлеге саны;
-районда яшәүчеләрнең китапханәләргә йөрү саны;
-квалификация күтәрү буенча курслар һәм тренинглар узган белгечләр саны;
- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ҮКСы» МБУ фондларына ел саен периодик басмалар керү
- «Кукмара муниципаль районы ҮКСы» МБУнең китап фондын ел саен яңарту;
- халыкның барлык катламнарыннан килүчеләрне җәлеп итү.

Ярдәмче программага
кушымта

**«2018-2020 ЕЛЛАРГА КИТАПХАНӘ ЭШЕН ҮСТЕРҮ» ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫ ЧАРАЛАРЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ФИНАНСЛАУ**

| № т/б | Чара исеме | Башка ручы | Үтәлү вакыты | Финанслау чыганагы | Чараны гамәлгә ашыруга чыгымнар (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | | | | | 2018 | 2019 | 2020 |
| **I** | **Мәдәни мирасны саклау, мәдәни традицияләрне үстерү һәм формалаштыру .** | | | | | | | |
| **1.1.** | **Мәдәният өлкәсе инфраструктурасын үстерү** | | | | | | | |
| 1.1.1. | Китапханә биналарын реконструкцияләү һәм ремонтлау китапханә | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | Республика бюджеты, муниципаль бюджет, бюджеттан тыш (алга таба – РБ, МБ, ВБ) | 150,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 |
| 1.1.2 | Учреждениеләрнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ, ВБ | 90,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| 1.1.3 | Район учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту. | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | РБ, МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 1.1.4 | Китапханә процессларын компьютерлаштыру һәм автоматлаштыру, техник тәэмин итү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | РБ, МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 1.1.5 | Китапханә биналарында АПС урнаштыру | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.6 | Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы укучылары өчен АРМнар оештыру | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | РБ, МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 1.1.7 | Автоматлаштырылган китап бирүне оештыру | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 1.1.8 | Үзәк китапханәләр системасына ЕЧБ кертү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 2 | **Мәдәният өлкәсендә кадрлар потенциалын саклап калу һәм яңарту** | | | | | | | |
| 2.1 | Китапханә хезмәткәрләре арасында «Елның иң яхшы китапханәчесе» исеменә район смотр-конкурсларын үткәрү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 2.2 | Аттестация комиссиясе, премияләү комиссиясе эшен оештыру | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 2.3 | Китапханә белгечләренең республика семинарларында катнашуын тәэмин итү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 2.4 | Китапханәләр өчен белгечләр әзерләү һәм яңадан әзерләү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 3 | **Гражданнарның район китапханә фондларының мәдәни һәм мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү** | | | | | | | |
| 3.1 | Китапханә фондын комплектлау | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | РБ, МБ, ВБ | 60,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 3.2 | Вакытлы матбугатка язылу | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | РБ, МБ, ВБ | 1500,0 | 500,0 | 500,0 | 500,0 |
| 3.3 | Шәхси БД китап фонды булдыру һәм эшләү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.4 | Фондны Электрон ресурслар белән тулыландырып тәэмин итү | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | РБ, МБ, ВБ | 33,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 |
| 3.5 | Медиатека булдыру һәм эшләү (СД-, видео -, слайд-, фоно -, аудио-фондлары) | ҮКС | 2018 – 2020 еллар | МБ,ВБ | 33,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 |
| 4 | **Район китапханәләренең белем бирү һәм мәдәни-агарту функцияләрен тормышка ашыру, күргәзмә һәм конкурслар оештыру.** | | | | | | | |
| 4.1 | Өстенлекле эш юнәлешләре нигезендә китап һәм укуны пропагандалау буенча зур комплекслы чаралар үткәрү<br>Кукмара районы китапханә хезмәте оешуга 100 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Француз шагыйре, әкиятче Ш.Перроның тууына 390 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Рус шагыйре Г.Р.Державинның тууына 275 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Рус шагыйре, тәрҗемәче В.А.Жуковскийның тууына 140 ел рус армиясендә беренче хатын-кыз офицер һәм язучы Н. А.Дурованың тууына 235 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 6,0 | 6,0 | | |
| | Рус язучысы И.С.Тургеневның тууына 200 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Рус драматургы А.Н. Островскийның тууына 195 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Француз язучысы Ж.Вернның тууына 190 ел, рус язучысы Л.Н.Толстойның тууына 190 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 6,0 | 6,0 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Швед язучысы С. Лагерлефның тууына 160 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Рус язучысы М. Горькийның тууына 150 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Язучы М. М. Пришвинның тууына 145 ел, рус опера җырчысы Ф.И. Шаляпинның тууына 145 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 6,0 | 6,0 | | |
| 4. | Татар язучысы Г.Исхакыйның тууына 140 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Татар язучысы Н. Думавиның, рус язучысы һәм драматургы А. Н. Толстойның тууына 135 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 6,0 | 6,0 | | |
| | Рус шагыйре В.В.Маяковскийның тууына 125 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Татар шагыйре, драматург Ф.Бурнашның, татар балалар язучысы Д. Аппакованың, татар язучысы һәм шагыйрь Г.Кутуйның, язучы Ш. Усмановның тууына 120 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 12,0 | 12,0 | | |
| | Татар язучысы Ә. Фәйзинең, татар драматургы Р. Ишморатның тууына 115 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| 4. | Татар язучысы Ф. Хөснинең, татар балалар язучысы А. Алишның, рус язучысы Б. Н. Полевойның, рус язучысы Н. Н. Носовның тууына 110 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 12,0 | 12,0 | | |
| | Шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе С. В. Михалковның тууына 105 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татар шагыйре М. Мазуновның, драматург Х.Вахитнең, рус шагыйре һәм тәрҗемәче Б. В. Заходерның, рус педагогы һәм язучысы В.А. Сухомлинскийның тууына 100 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 12,0 | 12,0 | | |
| | Рус язучысы А. И. Солженицынның тууына 100 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Татар балалар язучысы Л.Ихсанованың тууына 95 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 3,0 | 3,0 | | |
| | Татар шагыйрәсе Г. Зәйнашеваның, татар язучысы А.Гыйләҗевның татар язучысы Н. Фәттахның, татар балалар язучысы Ш. Галиевның тууына 90 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 12,0 | 12,0 | | |
| | Кыргыз язучысы Ч.Т.Айтматовның тууына 90 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 5,0 | 5,0 | | |
| 4.3 | Татар шагыйре һәм драматург И.Юзеевның, балалар шагыйре Х.Халиковның тууына 85 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 6,0 | 6,0 | | |
| 4.4 | Балалар шагыйрәсе Ә.Бикчәнтәеваның, Татарстанның халык шагыйре Ф.Яруллинның, татар шагыйре һәм рәссам Г. Сәгыйровның, рус актеры, шагыйрь С.Высоцкийның, рус язучысы Г.А. Вайнерның, рус язучысы В.П. Крапивинның тууына 80 яшь | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 18,0 | 18,0 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.8 | Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгына (1941 – 1945) чаралар циклы: ветераннар, сугыш чоры балалары белән очрашулар, китап күргәзмәләре, тематик кичәләр | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 25,0 | | | 25,0 |
| 4.46 | Татар язучылары һәм шагыйрьләре Ш. Мостафин, Р. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, А. Гаффарның туууына 70 ел | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 12,0 | 12,0 | | |
| | 2018 ел Татарстанда Лев Толстой елы дип игълан ителде Язучының иҗатын пропагандалаучы чаралар циклы | ҮКС | 2018 | МБ, ВБ | 10,0 | 10,0 | | |
| | ТАССР төзелүгә 100 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 5,0 | | | 5,0 |
| | Инглиз драматургы һәм шагыйрь У. Шекспирның тууына 455 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Рус язучысы, мәсәлче И.А. Крыловның тууына 250 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Рус шагыйре, прозаик, драматург А.С. Пушкинның тууына 220 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Казан университетына нигез салынуга 215 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Рус шагыйре, прозаик, драматург М. Ю. Лермонтовның тууына 205 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Рус рәссамы И.Е. Репинның тууына 175 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ♦ Татар шагыйре Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев), инглиз язучысы, Шерлок Холмсның «атасы» – А.К.Дойлның тууына 160 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 6,0 | | 6,0 | |
| | Татар драматургы һәм язучысының тууына Г.Камалның тууына 140 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Татар язучысы Ш. Камалның. тууына 135 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Рус шагыйре – А.А.Ахматованың тууына 130 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Татар шагыйре һәм тәрҗемәче С. Сүнчәләйнең, рус язучысы В.В.Бианкиның тууына 125 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 6,0 | | 6,0 | |
| | Татар язучысы Н. Исәнбәтнең тууына 120 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | ♦ Рус язучысы Н. А. Островскийның тууына 115 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | ♦ Татар шагыйре Ф. Кәримнең тууына 110 ел, татар язучысы Ә.Еникинең тууына 110 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 6,0 | | 6,0 | |
| | ♦ Рус язучысы – А.Гайдарның тууына 115 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | ♦ Татар композиторлары Ф.Яруллинның , Х. Вәлиуллинның, РФ халык рәссамы Х. Якуповның тууына 100 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 9,0 | | 9,0 | |
| | ♦ Рус язучысы – Ю. В.Бондаревның тууына 95 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татар балалар язучысы Р. Хафизованың татар язучысы Ш. Рәкыйповның, драматург һәм язучы Ш.Хөсәеновның, рус композиторы А.Н. Пахмутованың тууына 90 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 12,0 | | 12,0 | |
| | ♦ Татар язучысының Ф.Галиевның тууына 80 ел | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | ♦ Балалар язучысы, шагыйрь һәм прозаик Р. Бәшәрнең тууына 70 яшь | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | Шагыйрь һәм публицист Г. Моратның тууына 60 яшь | ҮКС | 2019 | МБ, ВБ | 3,0 | | 3,0 | |
| | ♦ Язучы А.С.Грибоедовның тууына 225 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Данияле язучы-әкиятче Х.К. Андерсенның тууына 215 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Татар язучысы һәм мәгърифәтче К.Насыйриның тууына 195 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Язучы А.П. Чеховның тууына 160 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Язучы, Нобель премиясе лауреаты И.А.Бунинның тууына 150 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Татар-башкорт язучысы М. Гафуриның, язучы А.С. Гринның, шагыйрь А.А. Блокның тууына 140 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 9,0 | | | 9,0 |
| | ♦ Инглиз язучысы А.Кристиның тууына 130 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ♦ Шагыйрь С. А.Есенинның тууына 125 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Татар композиторы С. Сәйдәшевның, татар шагыйре Х.Туфанның, француз язучысы А. де Сент-Экзюперинның тууына 120 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 9,0 | | | 9,0 |
| | ♦ Татар язучысы Ш. Маннурның, татар шагыйре Н. Баянның, совет язучысы М. А. Шолоховның тууына 115 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 9,0 | | | 9,0 |
| | ♦ Татар композиторы Җ. Фәйзинең, татар язучысы Н. Дәулинең, рус шагыйре А. Твардовскийның тууына 110 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 9,0 | | | 9,0 |
| | ♦ Шагыйрь К. М. Симоновның тууына 105 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Татар балалар язучысы Д. Тәрҗемановның тууына 100 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | Татар язучысы Г. Ахуновның, татар язучысы М. Насыйбуллинның тууына 95 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 6,0 | | | 6,0 |
| | ♦ Татар язучысы Б. Камаловның,татар язучысы һәм тәрҗемәче Х.Сарьянның, шагыйрә Р. Вәлиеваның, балалар язучысы М. Фәйзуллинаның, халык язучысы М. Мәһдиевнең тууына 90 ел | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 15,0 | | | 15,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ♦ Татар шагыйре Р. Әхмәтҗановка, татар язучысы В.Нуруллинга, Россия һәм Татарстанның халык артисты И. Шакировка, композитор Ф. Әхмәтовка, язучы М. Маликовага, язучы һәм драматург Т.Миңнуллинга, язучы Э. Касыймовка 85 яшь | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 24,0 | | | 24,0 |
| | ♦ Татар шагыйрәсе Л.Шагыйрьҗанга 75 яшь | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | | | 3,0 |
| | ♦ Татар шагыйрәсе Н. Измайловага, татар язучысы Р. Низамиевка, татар шагыйре Р. Шәриповка, язучы һәм публицист Ф. Бәйрәмовага 70 яшь | ҮКС | 2020 | МБ, ВБ | 12,0 | | | 12,0 |
| | ♦ «Җәй, китап, мин – дуслар» акциясен үткәрү | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| | Җәйге уку залын оештыру | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| | «Библиотөн» акциясе уздыру | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| | «Безнең күңелләрдә син, Тукай!» кече һәм урта мәктәп укучылары арасында шигырь укучылар, рәсем конкурсы) | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| | Актив укучыларны бүләкләү. Китапханәнең актив укучыларына шәхси фирма открыткалары – Рәхмәт хатлары, закладкалар чыгару | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мәгълүмати-библиография продукциясен бастыру, локаль программаларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 4,5 | 1,5 | 1,5 | 1,5 |
| 5 | **Районны бердәм мәгълүмати һәм мәдәни киңлеккә (пространство) кертү** | | | | | | | |
| 5.1 | китапханәнең WEB-сайтын даими яңарту | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 5.2 | Кулланучыларга хезмәт күрсәтү вакытында хокукый мәгълүмат Халык үзәге мөмкинлекләрен актив җәлеп итү | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 3,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| | Төрле профильдәге белгечләр белән партнерлык мөнәсәбәтләре урнаштыру: филологлар, журналистлар, язучылар, шагыйрьләр, китап басучылар, укытучылар, социологлар, психологлар белән. | ҮКС | 2018 – 2020 | МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| | Китапханәнең техник чаралары белән сервис хезмәтләре күрсәтү: ксерокопирование, компьютер хезмәтләре (җыю, сканерлау, текстларны бастырып чыгару) | ҮКС | 2018 – 2020 | ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районында оештырылган программаларда, конкурсларда һәм проектларда катнашу. | ҮКС | 2018 – 2020 | РБ, МБ, ВБ | 15,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Финанс-хуҗалык эшчәнлеге** | | | | | | | | |
| | Персоналга түләү чыгымнары | | | РБ, МБ, ВБ | 60379,1 | 21130,8 | 21109 | 18139,3 |
| | Хезмәт хакына начисление | | | РБ, МБ, ВБ | 18227,4 | 6375,4 | 6373,9 | 5478,1 |
| | Хезмәткә түләү фондыннан тыш, казна учреждениеләре хезмәткәрләренә башка түләүләр | | | МБ | 378,9 | 176,9 | 52 | 150 |
| | Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу | | | МБ | 9599,6 | 1451,1 | 6258,4 | 1890,1 |
| | Салым һәм җыемнар түләү | | | МБ | 147,4 | 52,2 | 46,2 | 49 |
| | **Барлыгы:** | | | | **91418,9** | **30113,9** | **34680,0** | **26625,0** |

## «2018 – 2020 елларга архив эшен үстерү» Ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга архив эшен үстерү» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның төп эшләүчесе | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге (алга таба – муниципаль архив) |
| Ярдәмче программаның максаты | 1. Җәмгыятьнең Татарстан Республикасы Архив фонды документларында һәм башка архив документларында саклана торган мәгълүматны алудагы агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру 2. Дәүләт идарәсе системасын документлар белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру |
| Ярдәмче программаның бурычы | 1. Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләренең сыйфатын һәм үтемлелеген арттыру;<br>2. Мәгълүмати ресурсларның сакланышын һәм тулылыгын тәэмин итү<br>3. Архив фонды документларын фәнни һәм иҗтимагый әйләнешкә кертү, Татарстан Республикасы Архив фонды һәм башка архив документларыннан тулысынча файдалануны тәэмин итү |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләмнәре | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме<br>2805,9 сум, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 ел – 1140,3 мең сум;<br>2019 ел – 992,6 мең сум;<br>2020 ел – 673,0 мең сум.<br>Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен аныкланырга тиеш |
| Ярдәмче | Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка |

| | |
|---|---|
| программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре – (елларга бүленгән нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | ашыру 2020 елга түбәндәге күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>муниципаль архив биналарының архив документларын даими саклауны тәэмин итүче норматив шартларга туры килү-килмәү дәрәҗәсенә ирешү 90,7 процентка кадәр;<br>реставрация, подшивка һәм переплет уздырылган архив документлары санын елына 200 берәмлеккә кадәр арттыру;<br>Татарстан Республикасының документаль мирасын популярлаштыруга юнәлтелгән чаралар санын елына өч берәмлеккә кадәр арттыру;<br>архивлар тарафыннан билгеләнгән срокларда башкарылган запрослар өлешен бер ел эчендә башкарылган запросларның гомуми күләменең 97,9 процентына кадәр арттыру; |

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сферасының гомуми характеристикасы, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

Татарстан Республикасы территориясендә архив эшен үстерү Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясендә Архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы, «Электрон имза турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 6 апрелендәге 65-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, шулай ук ведомствоара электрон документлар әйләнеше системалары турында, башкарма хакимият органнарында эш башкару кагыйдәләре турында, муниципаль берәмлекләр төзелгәнче, берләшкәнче, бүленгәнче яисә аларның статусы үзгәргәнче барлыкка килгән һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларында саклана торган архив документларына милекчелекне чикләү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән җайга салына,

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган һәм Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан берәмлекләрнең архив документларын саклау, комплектлау, исәпкә алу һәм куллану буенча аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль архивының документлар фондлары Татарстан Республикасы Архив фонды составына керә һәм Кукмара районының күп милләтле халкының тарихи, сәяси, икътисади, фәнни, социаль, мәдәни, матди һәм рухи мирасы, мәгълүмати һәм интеллектуаль байлыгының мөһим өлеше булып тора. Татарстан Республикасы

Кукмара муниципаль архивы – 40174 саклау берәмлеге булган 172 фонд. Шуларның 26810 саклау берәмлеге – идарә документлары; 13307 саклау берәмлеге – шәхси состав буенча документлар; 57 саклау берәмлеге – шәхси чыгыш документлары; 40 фотодокумент. Документлар 1930 – 2015 еллар белән даталана. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты архив бүлегенең документлар фондларында районның социаль-икътисади үсешен, аның үсешенең төрле этапларында яшәүче халык тормышын чагылдыручы мәгълүматлар бар. Алар ел саен мөһим тарихи һәм гамәли әһәмияткә ия булган документлар белән тулылана.

Электрон документ әйләнеше үсеше һәм оешмаларның эш башкару практикасында электрон документлар санын арттыру Татарстан Республикасы Архив фонды составын объектив рәвештә төр ягыннан эзлекле үзгәрешкә китерергә тиеш. Шуңа күрә муниципаль архивны электрон документларны кабул итүгә, саклауга һәм куллануга әзерләү, аларның аутентиклыгын (төп нөсхәгә тулысынча туры килә торган булуын) тәэмин итү – архив эшен үстерүнең өстенлекле юнәлеше.

Комплектлау чыганакларының составы яңадан каралды һәм киңәйтелде, шартнамә нигезендә дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм шәхси фонд хуҗалары белән хезмәттәшлеккә аерым игътибар бирелде.

Муниципаль архивны туплауда ел саен оешмаларда – комплектлау чыганакларында барлыкка килә торган даими саклау документлары күләменең артуы күзәтелә, шулай ук ябылган оешмаларның шәхси составы буенча кабул ителә торган документлар күләме дә арта.

2016 елда Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге архив документларын Озак вакытка саклау өчен архив учреждениеләренә куелган таләпләргә тулысынча туры килгән биналарга күчерелде. Кукмара муниципаль архивында иркен эш кабинетлары, клиентлар өчен урыннар, архив саклау урыннары бар.

Алга таба янгын һәм сакчылык куркынычсызлыгын ныгыту, муниципаль архивта температура-дымлылык режимын үтәү таләп ителә.

Сакланышны тәэмин итү чаралары системасында, архив документларын картонлаштыру өчен махсус чаралар кулланып, документларны картонлаштыру, тәрәзәләренә тимер рәшәткәләр урнаштыру аерым урын алып тора.

Бердәм мәгълүмати-аналитик системаны булдыру муниципаль архивның ачыклыгын сизелерлек арттыруга, заманча мәгълүмати технологияләрне куллану нигезендә архив документларын кулланунын үтемлелеген һәм нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк, профильле функцияләрнең үтәлешен оптимальләштерергә һәм архив фондларын исәпкә алу, саклау һәм идарә итүне яңа сыйфат дәрәҗәсенә чыгарырга китерәчәк.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль архивы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм үтемлелеген арттыру, шул исәптән электрон рәвештә хезмәт күрсәтүгә күчү – 2018-2020 елларга өстенлекле бурыч.

Дәүләт структуралары өчен архив – идарә итү документларын саклау һәм документлар белән идарә итү системасында экспертлар.

Фәнни җәмәгатьчелек вәкилләрен темаларның иң киң спектры һәм иң киң хронология кызыксындыра. Архивчылар һәм галим-гуманитарийлар арасында архив документларын өйрәнү, бастырып чыгару һәм экспонирование, кадрлар әзерләү өлкәсендә традицион рәвештә тыгыз хезмәттәшлек бар.

Безнең документаль мирасны өйрәнү һәм популярлаштыру өлкәсендә тикшеренүчеләр белән хезмәттәшлекне үстерергә кирәк.

Бу тема Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында» 2016 елның 11 гыйнварындагы УП-1 номерлы Указын гамәлгә ашыру контекстында аеруча актуаль.

Кукмара муниципаль районы муниципаль архивында ел саен Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә багышланган Батырлык дәресләре, дәрес-экскурсияләр, дәрес-күргәзмәләр үткәрелә. Чын документлар белән танышу һәрвакыт укучыларда зур тәэсир калдыра.

Фәнни җәмәгатьчелек белән хезмәттәшлек итүдә фәнни һәм тарихи-мәдәни әһәмияткә ия булган документларның сакланышын һәм сыйфатлы туплануын тәэмин итү өстенлекле бурыч булып тора. Бу эштә, аның үтемлелеген арттыру максатларында, документаль мирасны цифрлаштыру мөһим әһәмияткә ия.

**1 нче таблица Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында архив тармагы үсешенә SWOT-анализ**

| Көчле яклар (S) | Йомшак яклар (W) |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының социаль-икътисади, фәнни, инновацион потенциалы архив тармагының нәтиҗәле үсеше өчен шартлар тудырырга сәләтле. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы архив фонды зур мәгълүмати потенциалга ия, үз эченә идарә итү, шәхси чыгыш документлары, шәхси состав буенча документлар, традицион булмаган чыганаклардагы (аудиовизуаль) документларны ала. Документаль мәгълүмат ресурслары дәүләт һәм җәмгыятьнең ретроспектив мәгълүматларга булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында, шул исәптән гражданнарның конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен дә актив кулланыла.<br><br>Аудиовизуаль мәгълүматны саклау һәм | Архив эше өлкәсендәге законнар тармак үсеше ихтыяҗларына тулысынча җавап бирми.<br><br>документларны күчермәләү, реставрацияләү, консервация-профилактик эшкәртү өчен буш мәйданнар, махсус биналар булмау.<br><br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль архивы матди-техник базаны үстерүгә, шул исәптән компьютер паркын даими яңартуга, программа белән тәэмин итүгә мохтаҗ.<br><br>Бүлеп бирелә торган финанслау күләме районда архив тармагының эшләвен һәм үсешен тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирми.<br><br>Шәхси состав буенча махсус |

| | |
|---|---|
| куллану өлкәсендә яңа технологияләрне кертүнең уңай тәҗрибәсе булу һәм бу тәҗрибәне башка регионнарга таратырга әзер булу.<br><br>Архив хезмәткәрләренең алга таба үсеш потенциалы булган тәҗрибәле кадрлары булу | архивларның булмавы (бюджет, казна учреждениеләренең оештыру-хокукый формасы белән), муниципаль архивта кадрлар җитмәү |
| Үсеш мөмкинлекләре (O) | Мөмкин булган тышкы янаулар (T) |
| Татарстан Республикасы Архив фондының мәгълүмат потенциалы үсеше.<br>Мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне киң кертү нигезендә тармакның инновацион социаль-ориентлашкан үсешен **тәэмин итү**.<br><br>Муниципаль архив бинасының уңайлы инфраструктурасы һәм урнашуы кулланучыга үтемлелек логистикасының тиешле дәрәҗәсен тәэмин итәчәк.<br><br>Тармак тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр спектрын киңәйтү, электрон форматта күрсәтелә торган хезмәтләрне гамәлгә кертү. | Законнар белән җайга салуның камил булмавы һәм цифрлы контентның юридик әһәмиятен раслау буенча суд практикасының төрле мәгънәдә булуы.<br><br>Төзелә торган электрон документларның дөреслеген раслый торган электрон-цифрлы имза сертификатларының кыска вакытлы булуы.<br><br>Илдә финанс кризисы күренешләренә бәйле тотрыксыз икътисади вәзгыять һәм архив тармагы эшчәнлеген финанслау дәрәҗәсенең кимүе.<br><br>Мәйданнар җитмәү сәбәпле, архивларның туплануы туктатылу нәтиҗәсендә ведомство саклау этабында архив документларын югалту куркынычы.<br><br>Архив документларын кире кайтармаслык югалтуга китерерлек янгын куркынычы, гадәттән тыш хәлләр, шулай ук әйләнә-тирәлекнең җимерелүгә китерә торган (деструктив) факторлары барлыкка килү |

## II. Тормышка ашыру сроклары һәм этаплары, программа чаралары, шулай ук программаның максатлары, бурычлары һәм чаралары киселешендә нәтиҗәне бәяләү индикаторлары күрсәтелгән Программаның төп максатлары, бурычлары

Программаның максатлары һәм бурычлары «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү Стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеше Стратегиясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 25 сентябрендәге «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары Планын раслау турында» 707 номерлы карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары Планы белән билгеләнгән архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте өстенлекләренә туры килә, стратегик максатларга һәм бурычларга ирешүгә үз өлешләрен кертәләр.

Программаның төп максатлары:

1. Татарстан Республикасы Архив фонды документларында һәм башка архив документларында булган мәгълүматны алуга җәмгыятьнең агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру;
2. Дәүләт идарәсе системасын документлар белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

Программаның бурычлары:

1. Дәүләт идарәсенең аеруча әһәмиятле документларына ачык үтемлелек тәэмин итү;
2. Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләренең сыйфатын һәм үтемлелеген арттыру;
3. Архив документларын эзләү, тикшеренүләр һәм өйрәнү өчен үтемлелекне тәэмин итү;
4. Архив фонды документларын фәнни һәм иҗтимагый әйләнешкә кертү, Татарстан Республикасы Архив фонды һәм башка архив документларыннан тулысынча файдалануны тәэмин итү;
5. Чыганаклар һәм мәгълүмат йөртүчеләрнең эволюциясен исәпкә алып, фондларны сыйфатлы комплектлауны тәэмин итү;
6. Мәгълүмати ресурсларның сакланышын һәм тулылыгын тәэмин итү.

Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләрен тасвирлау, шулай ук чаралар киселешендә программаны финанслау аңа кушымта итеп бирелгән.

Программаны тормышка ашыру срогы – 2018 – 2020 еллар.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын куллануны күздә тота.

Программаны финанслауның гомуми күләме 2805,9 мең сум тәшкил итә:
2018 ел – 1140,3 мең сум;
2019 гел – 992,6 мең сум;
2020 ел – 673,0 мең сум.

Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү прогноз характерында һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Ярдәмче программаларның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру барышында түбәндәге социаль эффектларга ирешелә: программаның максатына – гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә Архив эше белән идарә итүгә ирешелә; Татарстан Республикасы Тарихи-мәдәни мирас мәгълүмат ресурсларының мөһим өлеше буларак, Татарстан Республикасы Архив фонды һәм башка архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм куллануны тәэмин ителә; юридик һәм физик затларның Татарстан Республикасы Архив фонды документларында һәм башка архив документларында булган мәгълүматны алу хокуклары гамәлгә ашырыла. Архив документларын популярлаштыру (күргәзмәләр, конференцияләр үткәрү, публикацияләр, документларны, шулай ук медиа чараларының сер булуын бетерү) чараларын гамәлгә ашыру республика халкын патриотик рухта тәрбияләү, Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең гомуми, мәдәни һәм белем дәрәҗәсен күтәрү өчен мөһим факторларның берсе булып тора. Мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләр үсеше хисабына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үтемлелеге һәм сыйфаты артачак. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә телекоммуникацион элемтә каналлары буенча электрон документлар алмашуны оештыру архив эше өлкәсендә дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге Программада каралган максатчан индикаторларның һәм күрсәткечләрнең факттагы казанышлары дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

Ярдәмче программага
кушымта

**"2018 - 2020 ЕЛЛАРГА АРХИВ ЭШЕН ҮСТЕРҮ" ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ**

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| Максат: җәмгыятьнең Татарстан Республикасы Архив фонды документларында һәм башка архив документларында саклана торган мәгълүматны алудагы агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру | | | | | | | | | |
| Бурыч 1: Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләренең сыйфатын һәм файдалану мөмкинлеген арттыру | | | | | | | | | |
| Архив документлары нигезендә хезмәт күрсәтү (юридик һәм физик затларга эшләр башкару) | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Архив бүлеге | 2018 – 2020 еллар | Бер ел эчендә башкарылган запросларның гомуми күләмендә билгеләнгән срокта архивлар тарафыннан башкарылган запросларның өлеше, процент | 97,5 | 97,9 | 97,9 | 170,75 | 170,75 | 170,75 |
| Бурыч 2: Архив фонды документларын фәнни һәм иҗтимагый әйләнешкә кертү, Татарстан Республикасы архивы фонды документларын һәм башка архив документларын тулысынча куллануны тәэмин итү | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасының документаль мирасын популярлаштыру, шул исәптән массакүләм | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 – 2020 еллар | Татарстан Республикасының документаль мирасын популярлаштыруга юнәлтелгән чаралар саны, | 1 | 2 | 3 | 170,75 | 170,75 | 170,75 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мәгълүмат чараларында | ның Архив бүлеге | | берәмлекләр | | | | | | |
| Максат 2:Дәүләт идарәсе системасын документлар белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | |
| Бурыч: Мәгълүмати ресурсларның сакланышын һәм тулылыгын тәэмин итү | | | | | | | | | |
| Архив саклагычларда янгынга каршы, сак, температура-дымлылык, яктылык, санитария-гигиена режимнарын тәэмин итү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Архив бүлеге | 2018 – 2020 еллар | Дәүләт архивлары биналарының архив документларын даими саклауны тәэмин итә торган норматив шартларга туры килү дәрәҗәсе, процент | 89,5 | 90,1 | 90,7 | 170,75 | 170,75 | 170,75 |
| Архив документларын реставрацияләү өчен җиһазлар сатып алу | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Архив бүлеге | 2018 – 2020 еллар | Кәгазьдә реставрация үткән, подшивка һәм переплет ясалган кәгазьдәге архив документлары саны, берәмлек | 100 | 150 | 200 | 628,05 | 480,35 | 160,75 |
| Ярдәмче программа буенча барлыгы | | | | | | | 1140,3 МБ | 992,6 МБ | 673,0 МБ |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

МБ – муниципаль бюджет